• КЫЙССА •
СӨЛӘЙМАН ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ
*5 бит*

• ВӘГАЗЬ •
АЯК КУЗГАЛМАС КӨН
*6 бит*

• НӘСЫЙХӘТ•
ДОГА ТӘКЪДИРНЕ ДӘ ҮЗГӘРТӘ
*12 бит*

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
ГАҖӘЕП КӨРӘШ
*14 бит*

№ 11 (316) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы рабигыль-әүвәл — рабигыль-ахыр, 1443
ноябрь, 2021

# دين ومعيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ




*Әни... Бу сүзгә күпме җылылык, ярату, наз салынган. Әни кешенең кадерен, үзең әни булгач кына белеп була, дигәннәр. Раббыбыз хатын-кызны шулхәтле олылап, аңа зур дәрәҗә биреп, әни дигән исемгә лаек иткән.*

*Дәвамы 13 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Казыйлар шурасы утырышы узды

*23нче ноябрьдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә Казыйлар шурасының чираттагы утырышы уткәрелде.*

Утырышта Татарстанның барлык төбәк казыйлары катнашты. Дин әһелләре көн тәртибендә халыктан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрне тикшерделәр, “ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә”нең тулыландырылган басмасын әзерләү һәм “Татар-мөселман исемнәре” китабын нәшриятка тапшыру буенча фикер алыштылар. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев әлеге басмаларны нәшер итүнең мөһим булуын гаилә кыйммәтләрен һәм татар-мөселман гореф-гадәтләрен саклау әһәмиятеннән чыгып аңлатты һәм гаиләне саклау буенча рухи-тәрбия бирү эшчәнлеген мөхтәсибәтләрдә киң җәелдерү буенча тәкъдимнәрен җиткерде.

Рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау уңаеннан фикер алышулар дөньякүләм билгеле мөселман галимнәре катнашында Татарстан казыйлары өчен махсус дәрестә дә дәвам итәчәк. Әлеге курслар мөселман гаиләләре эчендә конфликтларны хәл итү тарихын, теориясен һәм практикасын өйрәнүгә багышланган. Мөселман гаиләләре арасында гаилә бәхәсләре, хуҗалык мөнәсәбәтләренә кагылышлы хокукый мәсьәләләр белән бәйле низаглар һ.б. өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Курсларның актуальлеге дин әһелләрен конфликтларны дөрес җайга салырга, медиация мәсьәләләрен дөрес алып барырга өйрәтү, кешеләрне тыныч килешүгә китерү һ.б. белән аңлатыла.



Рәсәй ислам институты базасында Татарстан мөфтияте белән бергәлектә оештырылган әлеге курслар өчен казыйлар мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга һәм аның урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Рафикъ Мөхәммәтшинга зур рәхмәтләрен белдерделәр. Курсларның нәтиҗәләре буенча чираттагы Казыйлар шурасы утырышын 2022 елның 17 гыйнварында Буа шәһәрендә үткәрү планлаштырыла.

**dumrt.ru** сайтыннан

# Казанда казыйлар өчен махсус дәресләр үткәрелә



Фотолар dumrt.ru сайтыннан алынды

*Казанда Татарстан һәм Рәсәй төбәкләре казыйлары өчен “Ислам хокукында бәхәсләр гыйлеме” дип исемләнгән лекцияләр башланды. Дәресләр “Ислам дин белеменең заманча мәсьәләләре” квалификациясен күтәрү курслары кысаларында уза. Курсларда шулай ук Карачаево-Черкесия, Ингушетия республикасы, Саратов өлкәсе дин әһелләре катнаша.*

Дәресләрне биш көн дәвамында Рәсәй һәм чит ил галимнәре бирә. Мөхтәрәм лекторлар арасында ислам хокукы докторы, шәригать казые Ибраһим әл-Мурейхи (Бәхрәйн), ислам хокукы докторы, ислам суды буенча әйдәп баручы белгеч Абдуразак Буркыя (Марокко), ислам хокукы докторы, Димәшкъ университеты профессоры Бадигъ Ляхкам (Сүрия), ислам фәннәре докторы, КИУның дини фәннәр кафедрасы өлкән мөгаллиме Рөстәм хәзрәт Нургалиев, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Казан казые, Татарстан мөфтиятенең шәригать мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбарәков, КФУның Медиация, конфликтларны җайга салу һәм экстремизмны профилактикалау үзәге мөдире, доцент Олег Маврин, КФУ доценты, тарих фәннәре кандидаты Илшат Мөхәммәтзарипов һ.б. бар. Дәресләр Казанның “Давыдов” кунакханәсендә һәм дистанцион рәвештә ZOOM платформасы ярдәмендә уза. Модуль тәмамланганнан соң квалификация күтәрү курсларын узу турында таныклык тапшырылачак.

**dumrt.ru** сайтыннан

# Мәдрәсәләр арасында Рәсәйкүләм олимпиаданың төбәк туры үтте

***18нче ноябрьдә Казанда ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча олимпиаданың төбәк туры узды. Әлеге чарада Татарстанның һәм Идел буе-Урал төбәгенең урта һөнәри ислам уку йортлары шәкертләре көч сынашты. Олимпиаданы Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәниятенә һәм мәгарифенә ярдәм фонды булышлыгы белән Рәсәй ислам институты оештырды.***



Олимпиадада урта һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы II-III курс студентлары катнашты. Бәйге урта һөнәри дини белем бирү өчен төп һөнәри белем бирү программалары нигезендә төзелгән биремнәр буенча үткәрелде.

Катнашучылар олимпиада биремнәрен эшләргә керешер алдыннан Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ ректоры Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин нәсыйхәт сүзләрен җиткерде.

– Әлеге олимпиадада катнашуыгыз белем алган уку йортыгызда сезнең иң яхшы студент булуыгыз турында сөйли. Әйе, бүген барлык катнашучылар да призлы урыннар ала алмаячак, әмма бу сезгә белемнәрегезне арттырырга этәргеч бирергә тиеш. Тиздән Рәсәйкүләм олимпиада узачак, һәм бүгенге бәйге әлеге чарага яхшы әзерлек булачак, – диде Рафикъ Мөхәммәтша улы.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, быел биремнәр, нигездә, барлык номинацияләр буенча да компьютерда тест биремнәрен башкарудан гыйбарәт булды – бу хакта РИИ уку-укыту эше буенча проректор Марат Гыйльманов сөйләде.

– Быел олимпиадага яңалык керттек, өч номинация – ислам хокукы, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы һәм дисциплинаара фәннәр буенча компьютерда тестлар эшләнде. Һәр катнашучы теркәлү номерын алды һәм махсус сайтта биремнәрне башкарды. Жюри шундук гомуми нәтиҗәләрне алды. Бу – бик уңайлы һәм биремнәрне тикшерүне җиңеләйтә, – дип билгеләп узды Марат хәзрәт.

Өйлә намазыннан соң олимпиадага нәтиҗәләр ясалды. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында үтте. Ул сәламләү сүзе белән чыгыш ясады һәм галимнәргә хөрмәт күрсәтүнең әһәмияте хакында билгеләп үтте.

Аннары олимпиадада җиңүчеләр мөфти кулыннан бүләкләр алды. Җиңүчеләр түбәндәгечә билгеләнде:

**«Ислам хокукы» номинациясе**
1. Ярмөхәммәтов Самир – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе (Казан шәһәре).
2. Хубутдинов Эмиль – Мәрьям Солтанова ис. Ислам көллияте (Уфа шәһәре).
3. Әшрапова Алия – Ризаэтдин Фәхретдин ис. мәдрәсә (Әлмәт шәһәре).

**«Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы» номинациясе**
1. Рамазанов Йосыф — Мәрьям Солтанова ис. Ислам көллияте (Уфа шәһәре).
2. Алеев Салават — «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе (Казан шәһәре).
3. Бикбаев Мөхәммәд – Ислам динен кабул итүгә 1000 ел ис. мәдрәсә (Казан шәһәре).
4. Әшрапова Алсу — Ризаэтдин Фәхретдин ис. мәдрәсә (Әлмәт шәһәре).

**«Гарәп теле» номинациясе**
1. Курмаев Хәбибулла — «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе (Казан шәһәре).
2. Низамова Ләйлә — Ризаэтдин Фәхретдин ис. мәдрәсә (Әлмәт шәһәре).
3. Сабиров Азат – Мамадыш мәдрәсәсе.

**«Абсолют (дисциплинаара)» номинация**
1. Бекболот Уулу Кыялбек – Буа мәдрәсәсе.
2. Нәҗипов Давыд – "Ак мәчет" мәдрәсәсе (Чаллы).
3. Шиһапов Искәндәр — «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе (Казан шәһәре).

# Нәзарәт "30/40" проектында катнашырга чакыра



Фотолар dumrt.ru сайтыннан алынды

***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте "30/40" проектына катнашучылар җыя, әлеге чара 2022 елның 4-8 гыйнварында узачак. Проектта 30-40 яшьлек мөселманнар һәм мөслимәләр, шул исәптән, гаиләле парлар да катнаша ала. Барлыгы форумда 50 кеше катнашыр, дип ниятләнә. Язылу өчен телефон: 7 (843) 237-86-18. Шулай ук 2021 елның 25 декабренә кадәр Инстаграмда Muslimtol аккаунтына язарга, шулай ук Google Форманы тутырырга мөмкин.***

"30/40" проекты беренче тапкыр Татарстан мөфтияте тарафыннан 2020 ел башында тормышка ашырылды.

Бабаларыбыз рәсми рәвештә ислам динен кабул иткән тарихи җирлектә – Болгар шәһәрендә узачак форум "Пәйгамбәрләр эзеннән" дип исемләнгән. Катнашучылар Болгар ислам академиясе бинасында быелгы форумга махсус чакырылган дин белгечләреннән пәйгамбәрләрнең нәсыйхәтләрен һәм дәресләрен үзләштерәчәк, аларның тормыш юллары белән танышачак. Моннан тыш, биш көн дәвамында саф һавада тренинглар, остазлар катнашында дәресләр, иҗади һәм интеллектуаль бәйгеләр, спорт уеннары, тарихи Болгар шәһәре буйлап экскурсияләр, яңа танышулар һәм төрле темаларга фикер алышулар көтелә.

Әлеге форум Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү чаралары кысаларында оештырыла. Җыен татар милли киемнәре, милли ризыклар, татар халык йолалары һәм гореф-гадәтләрен пропагандалауны да үз алдына максат итеп куя, ягъни үзәктә татар мохитен тудыра торган стилизация булачак, катнашучыларга татар мәдәнияте үрнәген тәшкил иткән бүләкләр тапшырылачак. Татар халкының милли мирасын барлау һәм саклау – форум программасының төп өлешен тәшкил итә.

■ язмалар **dumrt.ru** сайтыннан алынды

# «Әдәпле надан тәрбиясез галимнән хәерлерәк»

*Ислам динендә күркәм әхлаклы шәхес тәрбияләү – төп максатларның берсе булып тора. Шәригать кануннары Коръәндә әхлакый кагыйдәләр, кешенең үз-үзен тотышы, эчке дөньясы, фикерләве белән тыгыз бәйләнештә бирелгән. Коръәндә тугрылык, ихласлылык, юмартлык, сүз һәм гамәл берлеге, шәфкатьлелек, ата-ананы хөрмәт итү, сабырлык һәм башка шундый күркәм әхлакый сыйфатлар мактала, аларның тискәреләре, киресенчә, төрлечә хөкем ителә.*

Ислам дине тынычлык, халыклар арасында дуслык булдыру, үзара ярдәмләшүне алга сөрә, кешеләрне бозыклык эшләүдән тыя.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе. [Олуг пәйгамбәрләр кебек, син дә чыдый алмаслык михнәтләрне кичерәсең]».**

«Әл-Каләм», 68:4

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә бер хәдисендә болай дип әйткән: «Мин күркәм әдәпне вә әхлакны югары рәвешкә җиткерер өчен җибәрелдем».

Ислам тормышның барлык өлкәләрендә дә әдәпле, тыйнак, сабыр, гүзәл әхлаклы булырга чакыра. Әдәпле булу өчен гыйлем кирәкме? Әйе, әйе! Акны карадан, яхшыны яманнан аера белү өчен азмы-күпме гыйлем кирәк булыр. Әмма ул гыйлем генә кешене галим дип санарга җитмәс, шуның өчен без аларны әлегә әдәпле надан исеме белән йөртик. Әдәплелек социаль киеренкелекне киметә һәм җәмгыятьтәге элемтәләрне ныгыту чарасы да булып тора. Әхлаклылык – милләт көченең нигезе, ә әхлаксызлык милләтнең таркалуына, түбәнгә тәгәрәвенә сәбәпче була.

Әдәпле надан кешеләргә игътибарлы, инсафлы була. Ул кеше һәрвакыт үзенең якыннары, дуслары турында кайгыртып яши, аларга гел ярдәм итәргә әзер тора. Әдәпле наданның кулыннан һәм теленнән һичкем зыян яки зарар, җәберзолым, кимсетүләр күрмәс, кеше малына кул сузмас, ислам дине кысаларына сыймаган сүзләр әйтмәс. Ул әдәпле инсан, надан булса да, барлык нәрсәләргә рәхмәт күзлеге аша карый. Ул үзенең Раббысына гөнаһ кылудан курка, ул тәкъва зат һәм шуңа да тәкъва кешеләр белән бергә булырга тырыша.

**«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Әдәпле надан шушы аятькә дә муафыйк рәвештә яшәргә тырыша дигән сүз. Бәлкем әле ул бу аятьнең барлыгын да белмидер.

Тәрбиясез вә әхлаксыз галимнәр хакында Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Кешеләрнең иң әхлаксызлары, явызлары – явыз галимнәрдер».

Ни өчен соң пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай дигән? Хакыйкатьтә, әхлаксыз вә тәрбиясез галимнәр белә торып гөнаһ кылалар. Белә торып гөнаһ кылу, белмичә кылганга караганда, күпкә начаррак, җәзасы да катырактыр. Аллаһы сакласын.



Фото: shutterstock.com

Хәдисләрдән аңлашылганча, тәрбиясез галимнәр әнә шундыйлардан. Аларның кайбер сыйфатларын санап үтик:

1) алган гыйлемнәре белән гамәл кылмыйлар;

2) гыйлемнәрен дөньяви максат өчен генә кулланалар;

3) халык алдында мактаналар, наданнар белән тарткалашалар; мәҗлесләрдә түрдә утырып, игътибарны үзенә генә юнәлдерергә, җәлеп итәргә тырышалар;

4) үзләрендә монафикълык чире, гамәлләре – риядыр;

5) кара көнчелек белән авырыйлар;

6) имамнарга буйсынмаслар, дин кагыйдәләренә җиңел карыйлар;

7) башкаларны түбәнсетәләр;

8) «Мин – галим» дип, масаеп йөрерләр;

9) дингә төрле яңалык, бидгать кертергә тырышалар;

10) тәкъва булып күренергә тырышып, кешеләр хакында начар уйлап сүз йөртәләр, гайбәт тараталар.

Аңлашылганча, тәрбиясез галим әле ул әхлаксыз да була, чөнки тәрбиясез генә, галимме ул яки наданмы, шундый гамәлләр кыла ала.

Әгәр дә галимнәр һәр эшне Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең Китабы – Коръәни Кәримне дөрес рәвештә аңлатып, тугры булсалар, мөселманнарның хакларын саклаган һәм дәрәҗәләрен төшермәгән булырлар. Киресенчә булса, алар явыз, әхлаксыз вә тәрбиясез галимнәр җөмләсеннән булырлар. Әдәпле наданның гамәлләре күпкә хәерлерәк, шәригать кысаларына сыярлык һәм кешелеклелек сыйфатлары ярылып ята. Тәрбиясез вә әхлаксыз галимнең эшләре исә хәерсез гамәлләр исәбеннән. Мондый гамәлләр кешеләрнең таркалуына, араларының кискенләшүенә, туганлык җепләренең өзелүенә, дошманлыкның артуына, ислам диненә мәхәббәтнең суынуына китерергә мөмкин. Аллаһы сакласын.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Игелекле гамәл кылсагыз, үзегезгә игелек кылган булырсыз. Начар гамәл кылсагыз – янә үзегезгә генә [чөнки начарлыклар өчен үзегезгә җавап тотарга туры киләчәк]».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:7

Без – кешеләр, бу дөньяда гамәлләр кылуда ирекле. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә разый булырдай яхшы гамәлләр дә, шулай ук Аның ачуына, җәзасына лаек булырдай начар гамәлләр дә кыла алабыз.

Бу аятьтән аңлашылганча: әдәпле надан үзенең гамәле белән үзенә игелек кыла, аның ахыргы урыны җәннәттә булыр, иншәАллаһ. Тәрбиясез галим дә үзе өчен гамәл кыла, тик ул кылган гамәлләрнең нәтиҗәсе начар, җәзага лаек.

Йә Раббым! Алган гыйлемнәребез әхлакларыбызны яхшы якка үзгәртергә ярдәм итсә иде. Һәммәбезгә дә әдәпле, тәрбияле, итагатьле бәндәләр булып яшәргә насыйп булсын. Әмин.

■ **Кәдим хәзрәт МӨБАРӘКШИН,**
Буа районы Килдураз авылы мәчете имам-хатыйбы

# Сөләйман галәйһиссәлам кыйссасы

***Давыд галәйһиссәламнең улы Сөләйман галәйһиссәлам... Исраиллеләр улларының бу бөек пәйгамбәре Аллаһы Тәгалә тарафыннан сайлап алынган һәм Аның күпләгән рәхмәтләре – хикмәт, гаделлек, байлык һәм тиңсез хакимлек белән бүләкләнгән. Сөләйман галәйһиссәлам җирдәге барлык җан ияләренең телләрен һәм башкаларның аңнарына сыймаган бик күп серләрне белгән. Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән белемнәрне һәм сәләтләрне ул кешеләрнең яшәешләрен яхшырту һәм аларны хак дин юлына чакыру өчен файдаланган. Сөләйманның хак патшалыгы турында дан-шөһрәт бар дөньяга таралган һәм ул әлегә кадәр Кәлам Шәриф битләрендә яши бирә.***


Фото: сайт dumrt.ru

### Сөләйман галәйһиссәлам тарафыннан чыгарылган карар

Бервакыт Сөләйманның әтисенә – патша һәм пәйгамбәр Давыд галәйһиссәламгә, килеп туган бәхәсләрендә гадел карар чыгару үтенече белән, ике кеше килгән. Берсенең сарыклары икенче бер кардәшенең йөзем бакчасына кереп, бер сабагын да калдырмыйча барлык чәчүлекләрне ашап бетергән. Давыд галәйһиссәлам аларга түбәндәге карар чыгаруы турында хәбәр биргән:

– Һәлак булган үсентеләр хисабына барлык сарыклар да бакча хуҗасына бирелергә тиеш.

Давыд галәйһиссәламнән чыккач, әлеге ике кеше Сөләйман галәйһиссәламне очратканнар һәм аңа барысын да сөйләп биргәннәр. Әмма, аларны тыңлап, Сөләйман галәйһиссәлам болай дип җавап биргән:

– Әгәр мин сезнең мәсьәләне караган булсам, башка карар кабул иткән булыр идем.

Сөләйман галәйһиссәламнең сүзләре кичекмәстән Давыд галәйһиссәламгә билгеле булган. Ул үзенә улын чакырытып алган һәм ике кешенең бәхәсе буенча аның фикерен сораган. Сөләйман галәйһиссәлам болай дип җавап биргән:

– Сарыклар беркадәр вакытка бакча хуҗасына бирелергә тиеш. Ул чагында дөньяга килгән бәрәннәр, шулай ук сөт һәм йон аныкы булачак. Ә юкка чыгарылган бакча сарык хуҗасына бирелергә тиеш, кайчан да кайчан бакча элеккеге халәтенә килеп, җимеш бирә башлагач, ул хуҗасына кайтарылып бирелсен. Минем карашка, бу иң дөрес карар.

Улын тыңлаганнан соң Давыд галәйһиссәлам аның белән килешкән һәм моны иң дөрес, гадел карар дип таныган.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**"Без аны Сөләйманга [галәйһиссәлам] аңлаткан идек. Һәрберенә дә хөкем [пәйгамбәрлек] һәм гыйлем биргән идек. [Тәсбих белән мәшгуль булган вакытта] Давыд [галәйһиссәлам] белән бергә тауларны һәм кошларны әмергә буйсындырдык ки, алар [үз телләре белән Безне мактап] тәсбих әйтәләр иде. [Моның кебек эшләр сезгә бик кызык булса да] Без [бөек пәйгамбәрләргә моның кебек могҗизаларны бирү эшен] кылучылар булдык".**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:79

### Бала кемнеке?

Ике хатын-кыз яшәгән. Һәм бу хатын-кызларның һәрберсенең дә бер яшьләр тирәсендәге балалары булган. Бервакыт алар сабыйларын ияртеп, һава сулап йөреп кайтырга чыгалар. Әмма яшь әниләр игътибарсызлык күрсәтәләр: бүре бер баланы эләктереп алып китә, һәм хатын-кызлар аны коткару өчен берни дә эшли алмыйлар.

Бу ике хатын-кыз арасында исән калган балага бәйле бәхәс килеп чыккан. Аларның берсе: "Бүре синең балаңны алып китте, ә бу минем бала", – дип әйткән. Икенчесе: "Юк, бу минем бала, бүре синең балаңны алып китте", – дип үз сүзен дөреслеккә чыгарырга теләгән.

Әлеге бәхәсне хәл итү өчен, баланы алып, Давыд галәйһиссәлам янына барганнар. Мәсьәлә бик катлаулы булган, чөнки ике хатынның берсе дә юл бирергә теләмәгән, һәм аларның сүзләрен раслаучы яки кире кагучы шаһитлар да булмаган. Озак кына уйлаганнан соң Давыд галәйһиссәлам яше буенча өлкәнрәк хатын-кызны яклап чыккан, икенче хатын-кыз исә моның белән килешмичә барысын да Сөләйман галәйһиссәламгә сөйләп биргән. Пәйгамбәр аны тыңлап, болай дип җавап биргән:

– Әгәр сез чыгарылган карар белән килешмәсәгез, баланы урталайга чабыгыз. Ул сезнең икегезгә яртылаш эләксен – икегезгә дә бала булыр.

Карарның коточкыч булуына да карамастан, өлкән хатын-кызны бу тәкъдим канәгатьләндергән, һәм ул баланы урталай ярырга рөхсәт биргән. Ә менә икенчесе, бала гомере өзелүдән куркып, үзенең дәгъваларыннан баш тартып: "Баланы ярмагыз. Мин баладан баш тартам, ул аңа булсын", – дип әйткән.

Шуннан соң Сөләйман галәйһиссәламгә аларның кайсысының чыннан да яратучы әни булуы ачыктан-ачык аңлашылган. Ул баланы газапламас өчен аның белән аерылышуны артыграк күргән әнигә сабыйны биргән.

Хәзер инде баласын бүре алып киткән өлкән хатынның, шушы кайгылы көннәр авыр мизгелләр булып күз алдына килеп басмасын дип, чит баладан котылырга әзер булуы да аңлашылган.

*(Дәвамы бар)*

■ **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
Татарстан Республикасы мөфтие

## Сөләйман галәйһиссәламнең кырмыска белән очрашуы

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Җеннәрдән, кешеләрдән һәм кошлардан торган гаскәрләр Сөләйман [галәйһиссәлам] янына җыелды».**

«Нәмел / Кырмыска», 27:17

Шам тарафында күп кырмыскалар булган кырмыскалы чокырга җиткәндә, бер кырмыска: «Әй, кырмыскалар, үзегезнең урыннарыгызга качыгыз, Сөләйман үзенең гаскәре белән килә, күрмичә сезне таптамасын. Алар белсәләр, таптамас иделәр», – диде, гүя ки ул кырмыска пәйгамбәрләрнең золымлыктан һәм нахак газаплаудан, рәнҗетүдән пакь булуларын сизде. Сөләйман галәйһиссәлам ул кырмысканың саклануыннан һәм башка кырмыскаларны саклындыруыннан, шулай ук үз мәслихәтен белүеннән гаҗәпләнеп көлде һәм әйтте:

**«Ий Раббым! Миңа һәм ата-анама биргән ниґъмәтеңә шөкер итүемне, [калган гомеремдә] Син разый булган бер гамәл эшләвемне миңа илһам ит һәм рәхмәтең белән мине изге колларың [булган Ибраһим, Исмәгыйль һәм Ягъкуб (галәйһимуссәлам) кебек элекке пәйгамбәрләрең] арасына керт».**

«Нәмел / Кырмыска», 27:19

Хәбәр ителгәнчә, Сөләйман галәйһиссәлам кырмыскадан бу сүзне ишетеп дога кылгач, җилгә тәхетне туктатырга, кырмысканы чакырырга кушты. Кырмыска килеп сәлам бирде. Сөләйман галәйһиссәлам: «Ни өчен башка кырмыскаларны коткарып, үзең качмадың?» – дип сорады. Кырмыска: «Мин аларның патшалары, минем исемем Җәмәлик, олыларга халыкка карата шәфкатьле булу тиештер. Аларны бәладән качырдым, бәла килсә, үземнең өстемә алдым», – диде. Моннан соң кырмыска үзенең гыйлемен белдерү өчен: «Әй Сөләйман! Исемеңнең мәгънәсе нинди?» – дип сорады. Сөләйман галәйһиссәлам: «Исемемнең мәгънәсен үзең әйт», – диде. Кырмыска: «Исемеңнең мәгънәсе – Ахирәт хәлен күрми торып, сәламәт булган күңелдер. Әй Сөләйман! Хак Тәгалә сиңа ни нәрсә бирде?» – дип сорады. Сөләйман галәйһиссәлам: «Хак Тәгаләдән миннән соң беркемдә дә булмый торган патшалык сорадым», – диде. Кырмыска әйтте: «Бу сүздән көнчелек исе киләдер. Янә Хак Тәгаләдән тагын нәрсә сорадың?» Сөләйман галәйһиссәлам: «Хак Тәгалә миңа җилне буйсындырды, бер көндә бер айлык җирне үтәрмен», – диде. Кырмыска әйтте: «Җилнең мәгънәсе шул булыр: бу синең кулыңда булган мал-мөлкәт җил кебек ышанычлы булмас. Җилгә нинди таяныч булуы мөмкин?! Әгәр сабыр булсаң, Хак Тәгалә сиңа мәгърифәт атын бирер һәм күз ачып йомганчы Гарешкә барып килер идең. Хак Тәгалә сиңа тагын нәрсә бирде?» – диде. Сөләйман галәйһиссәлам: «Бер йөзек бирде, шушы йөзекне күреп, барча адәм, җен, кош-корт миңа буйсынды», – диде. Кырмыска әйтте: «Синең барча мөлкәтең бер дирһәм таш кыйммәтендә икән. Хак Тәгалә сиңа тагын ни бирде?» Сөләйман галәйһиссәлам: «Дию-пәриләрне миңа буйсындырды», – диде. Кырмыска әйтте: «Аларны ник кабул иттең? Әгәр Хак Тәгаләдән фәрештәләрне теләсәң, сиңа фәрештәләрне бирер иде. Яки һичнәрсә теләмәсәң, Хак Тәгалә каршында артык сөекле булыр идең. Оҗмахка кергәндә, пәйгамбәрләрдән соң калмас идең», – диде. Дәүләтләре булу сәбәпле, Йосыф белән Сөләйман галәйһиссәлам пәйгамбәрләрдән кырык ел соңрак оҗмахка керерләр, дип әйтелә. Сөләйман галәйһиссәлам ул сүзне ишетеп, патшалыктан күңеле суынды һәм әйтте: «Әй, кырмыска, бу гыйлемне кайдан белдең?» Кырмыска: «Раббым өйрәтте», – диде. Хак Тәгалә балык һәм кырмыска белән вәгазь кылды. Сөләйман галәйһиссәлам һәрвакыт гыйбадәт кылыр иде, шуның өчен Коръәни Кәримдә: «Нинди хуш кол!» – дип макталды.

■ **"Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы"** китабыннан

# Аяк кузгалмас көн


Фото: shutterstock.com

***Барча галәмнәрне Яратучы, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булсын! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, ныклы сәламәтлек насыйп итсә иде!***

Татар халкында бер тирән мәгънәле әйтем бар: «өч көнлек дөнья». Бу сүзләр нигезсез барлыкка килмәгән. Исламдагы борынгы галимнәребез дә шул ук сүзләрне әйтеп калдырганнар. Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи исемле табигыйн: «Бу дөнья 3 көннән тора: кичә, бүген, иртәгә. Кичәге көн инде барлык әйберләре белән үтеп китте. Иртәгә синең өчен килеп тә җитмәскә мөмкин. Синең көнең – ул бүген. Шуңа да аны кыйммәтлә һәм иң яхшы рәвештә куллан», – дип әйтеп калдырган. Шул сәбәпле, без бу дөньядагы һәр көнне кадерләп, кылган гамәлләребезне уйлап яшәргә тиешлебездер. Ә ни өчен? Вәгазебезнең темасына якынрак килеп әйтсәк, чөнки аяк кузгалмас көндә бу гамәлләребез барысы өчен дә җавап бирәсе булачак бит.

Кыямәт көненә, үлгәннән соң терелүгә ышану – иман баганаларының берсе булып тора. Мөэмин-мөселман моңа ышана, иман китерә һәм анда аны Аллаһы Тәгаләнең хисабы көтәчәген яхшы белә.

Бу көннең кайчан җитәсен, анда нәрсәләр буласын Аллаһы Тәгалә генә белә. Әмма без Аллаһы Тәгалә Үзе һәм Аның пәйгамбәре Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйтеп калдырганнардан чыгып, гел бу көнне искә алырга, анда булачак вакыйгалар – хисап тоту, гамәлләрнең үлчәнүе, Сират һәм башкалар турында уйланырга тиешлебездер.

Бәрзах тормышы тәмамланганнан соң, Кыямәт көне җитәр. Исрафил галәйһиссәлам сурга өреп, җаннар кабаттан үз тәннәренә кайтырлар. Һәм хәтта бу көнне инкяр иткән кешеләр дә аның хаклыгын аңларлар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«[Икенче мәртәбә] Сурга өреләчәк. Һәм менә алар [яткан] каберләреннән [торып] ашыга-ашыга, Раббыларына ашыгырлар. Алар [мәхшәр дәһшәтенә нисбәтле кабер газабын йокы дип санаучылар]: «Ни үкенеч безгә! Безне йоклаган җиребездән кем торгызды?» – дип әйтерләр. [Шулвакыт фәрештәләр]: «Бу – Рахман [булган Аллаһы] вәгъдә иткән нәрсә. Җибәрелгәннәр [терелтелеп, хисапка тартылачагыгызны белдергән чакта] дөресен сөйләгән булганнар» [дип әйтерләр]».**

«Йәсин», 36:51-52

Каберләреннән кубарылып, кешеләр мәхшәр мәйданына җыела башларлар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләрнең бу мәйданга җыелу рәвеше дә төрле була дип әйтте. Изге гамәл кылучыларга фәрештәләр киемнәр кидертерләр, алларында һәм артларында нур булган кешеләр дә булыр. Аларның кайберләре җәяү, кайберләре атланып киләчәкләр. Әмма җирдән аяклары белән атлап түгел, йөзләре белән өстерәлеп килүчеләр дә булачак. Аллаһы сакласын!

Кыямәт көненең икенче исеме Хисап көне. Бу, чыннан да, бөек, гадел хисап көне булачак. Кемнәрнедер, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә хисапсыз җәннәтле итәчәк, тик кемнәргәдер бу хисапны тотарга туры киләчәк. Хисап та һәр кеше өчен төрле булачак: кемгәдер аны үтү авыр булачак, кемгәдер – җиңел.

Хисап турында күпме генә әйтсәк тә, без аны күз алдына да китерә алмыйбыз. Әмма Аллаһы Тәгалә безгә шул хисапка әзерләнер өчен бу тормышны бирде. Һәм безгә Ахирәтебезне кайгыртып, бу тормышта аңа ныклы итеп әзерләнергә кирәктер, чөнки Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе болай дип әйтеп калдырды: «Бүген – хисапсыз гамәл көне, иртәгә – гамәлсез хисап көне».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә дүрт төрле әйбер турында соралмый торып, кеше аягын да атлый алмаячак. Тормышы турында: аны ничек итеп үткәрде. Гыйлеме турында: ул аны нәрсәгә кулланды. Малы турында: ничек итеп кәсеп кылды һәм нәрсәгә сарыф итте. Тәне турында: аны ничек итеп кулланды».

Дөньяга туган һәр кешегә бирелә торган әйбер – гомер. Озынмы ул, кыскамы, бәхетле гомерме ул, юкмы, әмма һәр кешенең аңа бүленеп бирелгән гомере бар. Икенче төрле тормыш дип тә әйтергә буладыр. Һәм, әлбәттә, кеше Кыямәт көнендә тормышы хакында сораläчак. Бирелгән гомерен гыйбадәттә, изгелектә, Аллаһы Тәгалә кушкан юлда булып үткәрдеме? Әллә киресенчәме? Кемдер чирек гасыр яшәп тә, Ахирәте өчен багаж тупларга тырышып калган була, ә кемдер бер гасыр яшәп тә, вакытын бушка уздырудан кала еракка китмәгән була. Әмма онытмыйк, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Икенче соралачак нәрсә – гыйлем: безнең җирлекне алып карасак, баланы инде балалар бакчасында укырга-язарга өйрәтә башлыйлар, аннан соң ул 11 ел мәктәптә гыйлем ала. Аны тәмамлагач, югары уку йортында тагын биш ел укый, аннан соң магистратурада – ике ел, аннан аспирантурада 3 ел укый. Шулай итеп, 20 елдан артык вакыт бертуктаусыз гыйлем алуга гына кайтып кала. Ә хәзер үзегезгә үзегез сорау бирегез: тормышыбызның никадәр вакытын без дини гыйлем алуга юнәлтәбез? Дөреслектә, кеше бар гомерен гыйлем алуга юнәлтергә тиеш, чөнки Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем алыгыз», – дип әйтеп калдырган. Ә Кыямәт көнендә кеше үзенең гыйлемен ни рәвешле алганын, ул гыйлемне нинди юлда кулланганы өчен җавап тотачак.

Өченче соралачак нәрсә – мал. Кеше малны ничек тапканы, аны кайларга сарыф иткәне турында соралачак. Гөнаһ һәм изгелекнең тузан бөртеге кадәрлесе дә билгеле булган кебек, монда да, һәрбер тоткан тиенебез өчен дә җавап көтә.

Шулай ук, кешедән тәне турында да сораячаклар. Барыбыз да тәнебезнең безнең өчен әманәт икәнен яхшы беләбез. Шуңа да, тәнебезгә карата нинди мөнәсәбәттә идек: авыру килсә, аны сәламәтләндерергә тырыштыкмы, аны хәләл ризык белән тукландырдыкмы – болар барысы да соралачак. Кулларыбыз белән нәрсә тоттык, ни эшләдек, аякларыбыз белән нинди җирләргә бардык: харам кылына торган җирләргәме, әллә инде Аллаһыны искә ала торган урыннаргамы?

Кыямәт көнендә кешегә бу һәм башка сораулар бирелер. Изге гамәлләре вә гөнаһлары күрсәтелер. Беркая да качып булмас! Дәшмичә генә калырга уйласак та, ул безгә һич булыша алмас. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Ул көнне [кылган гөнаһларны инкяр итәр өчен кискен бер сүз көрәштерүгә керешкән чакларында] аларның авызларын мөһерләрбез һәм [дөньяда] аларның ни кылганнарын куллары сөйләр, аяклары шаһитлык итәр».**

«Йәсин», 36:65

Әмма гөнаһ кылып, Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәмичә, тыйганнарыннан тыелмыйча йөргән кешеләргә дә татар халкының тагын бер әйтеме бар: унбиш көннең «бәйрәме» бер була! Бәйрәм дигәндә, әлбәттә, киная ятканын аңлагансыздыр. Син әле яшь, син әле көчле, син әле бай кебек сүзләргә алданып яшәмик! Бүген акча җыям, иртәгә садака бирермен дип алданмыйк, иртәгә үк фәкыйрьлек килергә мөмкин. Яшь вакытта эшләп калыйм, картайгач мәчеткә йөрермен димик, картлык белән гәүдәгә зәгыйфьлек килеп, селкенергә дә кыен көннәр җитәргә мөмкин. Ә иң мөһиме, шуларга алданып, шушы «унбиш» көн үтәчәк. Һәм инде Аллаһы Тәгалә каршына баскач, бары тик җавап бирү генә кала. Бернинди гамәл кылып булмас: намаз укып, садака биреп, сөйләшмәгән туганнарыбыз белән яхшы мөгамәлә корып та. Бары тик хисап тоту гына булачак.

■ **Шамил хәзрәт ӘХМӘТГАЛИЕВ,**
Арча районы, Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы

# Йокыдан уяну һәм йокларга яту белән бәйле догалар

Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә: **“Аллаһы [әҗәле җиткән] җаннарны үлемнәре вакытында [тулысынча] ала, үлмәгәннәрне [үлемнәре җитмәгәннәрне] исә йокыларында [ала, үлем җиткәч, тулысынча; йокыда чакта исә өлешчә ул рухларның бәдәннәре белән бәйләнешен өзә]. Ул үлем карары биргәннәрне тота [һәм бәдәннәренә кире җибәрми]. Бүтәннәрен исә [үлемнәре] билгеләнгән вакытка кадәр [бәдәннәренә] җибәрә. [Аллаһы Тәгаләнең тиңсез эшләрендәге өстен хикмәтләрне] Фикерләгән кешеләр өчен монда билгеләр бар”.**

«Әз-Зүмәр / Тәркемнәр», 39:42

Динебез буенча без йокларга яту әдәпләрен булдыра алганча үтәргә һәм көнкүреш гадәтенә әйләндерергә тиеш. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йокларга тәһарәт белән ятарга кушуын беләбез. Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырылган хәдистә Расүлебезнең әлеге сүзләре риваять ителә: “Фәрештә тәһарәт белән йоклап киткән кеше янында төн үткәрә һәм һәрвакытта да бу кеше уянганда, ул “Йә Аллаһым! Үзеңнең фәлән колыңны гафу ит, дөреслектә, ул тәһарәт белән йоклады”, – дип әйтә (Ибне Хиббән, Ибне Мөбарәк)”.

Тыйб (медицина) ягыннан йоклар алдыннан йокы булмәсен җиллэтеп алу, иркен кием кию киңәш ителгән кебек, динебез буенча да без тәһарәтле хәлдә йокларга яту һәм кайбер махсус догаларны уку тәртибе белән таныш булырга тиеш. Аларны карап үтик.

## Иртән торгач укыла торган дога

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى اَحْيَانَا بَعْدَ مَآ اَمَاتَنَا وَاِلَيْهِ الْبَعْثُ وَ النُّشُورْ

“Әлхәмдү лилләәһи-лләҙии әхйәәнәә бәгъдә мәә әмәәтәнәә вә иләйһил-бәгъсү вән-нүшүүр”.

«Безне үлгәннән соң терелтүче Аллаһыга мактау булсын! Үлгәннән соң терелтү Аллаһыдандыр, кайту да Аңадыр».

## Йокларга ятканда укыла торган дога

بِاسْمِكَ اللَّهُمَّ اَمُوتُ وَاَحْيَى

“Бисмикә-ллаһуммә әмүүтү вә әхйәә”

«Аллаһым! Синең исемеңне хәтерләп үләм һәм яшим».

Йокларга ятканда укыла торган башка бер дога:

بِاسْمِكَ رَبِّى وَضَعْتُ جَنْبِى وَبِكَ أَرْفَعُهُ إِنْ أَمْسَكْتَ نَفْسِى فَارْحَمْهَا وَإِنْ أَرْسَلْتَهَا فَاحْفَظْهَا بِمَا تَحْفَظُ بِهِ عِبَادَكَ الصَّالِحِينَ

«Бисмикә раббии вәдагъту җәнбии вә бикә әрфәгуһү ин әмсәктә нәфсии фәрхәмһәә вә ин әрсәлтәһәә фәхфәҙһәә бимәә тәхъфәҙу биһи гыйбәәдәкәс-саалихиин».

“Әй Раббым! Синең исемең белән яттым. Тагын Синең исемең белән торырмын. Аллаһым! Әгәр йоклаганда җанымны алсаң, миңа мәрхәмәтле бул, әгәр яшәтсәң, яхшы бәндәләреңне саклаган кебек, минем тормышымны да сакла!”

Пәйгамбәребезнең йокларга ятканда шушы доганы укуы да риваять кылынган:

اللَّهُمَّ أَسْلَمْتُ وَجْهِى إِلَيْكَ وَفَوَّضْتُ أَمْرِى إِلَيْكَ وَأَلْجَأْتُ ظَهْرِى إِلَيْكَ رَهْبَةً وَرَغْبَةً إِلَيْكَ لَا مَلْجَأَ وَلَا مَنْجَى مِنْكَ إِلَّا إِلَيْكَ آمَنْتُ بِكِتَابِكَ الَّذِى أَنْزَلْتَ وَبِنَبِيِّكَ الَّذِى أَرْسَلْتَ.

«Аллааһүммә әсләмтү вәҗһии иләйкә вә фәввадтү әмрии иләйкә вә әлҗәәтү ҙаһрии иләйкә раһбәтән вә рагъбәтән иләйкә ләә мәлҗә-ә вә ләә мәнҗәә минкә илләә иләйкә әәмәнтү бикитәәбикәл-ләҙии әнзәлтә вә бинәбиййикәл-ләҙии әрсәлтә».

“Аллаһым! Үземне Сиңа тапшырдым, эшемне Сиңа калдырдым, аркамны Сиңа сөядем. Сиңа таяндым. Синнән өмет итеп һәм Синнән куркып, тагын Сиңа килдем, Аллаһым! Синнән башка сыеначак башка урын юктыр. Аллаһым! Индергән китабыңа, күндергән Пәйгамбәреңә инандым”.

## Йоклаганда курыккан кеше укый торган дога

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّآمَّاتِ مِنْ غَضَبِهِ وَشَرِّ عِبَادِهِ وَمِنْ هَمَزَاتِ الشَّيَاطِينِ وَأَنْ يَحْضُرُونَ

«Әгүүҙү бикәлимәәтилләәһиттәәммәәти мин гадабиһи вә шәрри гыйбәәдиһи вә мин һәмәзәәтишшәйәәтыыйни вә ән йәхъдуруун».

“Бөтен шәйтаннардан, зәһәрле хайваннардан һәм күзе тигән һәр начар күздән Аллаһы Тәгаләнең кимчелексез һәм тулы кәлимәләренә сыенамын”.

## Төнлә уянган кешенең укый торган догасы

لَآ إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ. وَالْحَمْدُ لِلَّهِ وَسُبْحَانَ اللَّهِ وَلَآ إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَ اللَّهُ أَكْبَرُ وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ.

«Ләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһ. Ләһүл-мүлкү вә ләһүл-хәмду вә һүә галәә кулли шәй-ин кадиир. Вәлхәмдү лилләәһ. Вә сүбхәәнәллааһи вә ләә иләәһә илләллааһү вәллааһу әкбәр вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһ».

“Аллаһыдан башка илаһ юк. Аның дусты һәм охшашы да юк. Мөлек — Аныкы, Мактау да — Аңадыр. Аның һәрнәрсәгә көче җитә. Мактау — Аңадыр. Аны тәсбих итәм. Аннан башка илаһ юк һәм Ул һәрнәрсәдән бөектер. Көч һәм куәт иясе Ул гынадыр”.

Пәйгамбәребез төннәрен уянган вакытта шушы доганы да укый торган булган:

لَآ إِلَهَ إِلَّآ أَنْتَ سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ أَسْتَغْفِرُكَ لِذَنْبِى وَأَسْئَلُكَ رَحْمَتَكَ. اللَّهُمَّ زِدْنِى عِلْمًا وَلَا تُزِغْ قَلْبِى بَعْدَ إِذْ هَدَيْتَنِى وَهَبْ لِى مِن لَدُنْكَ رَحْمَةً إِنَّكَ أَنْتَ الْوَهَّابُ

«Ләә иләәһә илләә әнтә сүбхәәнәк. Аллааһүммә әстәгъфирукә лиҙәнбии вә әс-әлүкә рахмәтәкә. Аллааһүммә зиднии гыйльмән вә ләә түзигъ кальбии бәгъдә иҙ һәдәйтәнии вә һәблии мин ләдункә рахмәтән иннәкә әнтәл-вәһһәәбе».

“Аллаһым! Синнән башка илаһ юк. Сине тәсбих итәмен. Аллаһым! Гөнаһларым өчен Синнән мәгъфирәт сорыйм. Синең рәхмәтеңне телим. Аллаһым! Гыйлемемне арттыр, һидаятькә ирештергәннән соң күңелемне адаштырма. Үз тарафыңнан миңа мәрхәмәт кыл, чөнки Син күп бирүчесең”.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм түшәккә ятканда кулларын берләштерә һәм «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен укып, учларына өрә һәм өч мәртәбә тәнен сыйпый торган иде.

Монда без ана телебездә укылырга һәм балаларыбызга өйрәтергә мөмкин булган бер дога китереп узабыз:

«Аллаһым! Синең исемең белән ятамын. Синең исемең белән торырга насыйп ит. Миңа, ата-анама, кардәшләремә һәм гаилә әгъзаларына сәламәтлек һәм сихәт бир. Безгә дәресләребездә, эшләребездә уңышлар бир, ярдәмеңнән ташлама. Дөньяның башка мәмләкәтләрендә яшәгән һәм Сиңа инанган, бәйсезлекләрен югалткан кардәшләребезгә ярдәм кулын суз, Аллаһым!»

## Матур төш күрү өчен укыла торган дога

Ятканда бу доганы укыган кеше гүзәл төш күрер дип өмет ителә. Шуңа өстәмә итеп, ятар алдыннан ястү намазын укып, югарыда китерелгән догаларның кайберләрен укырга кирәк.

نُؤْمِنُ بِاللَّهِ نَثِقُ بِاللَّهِ نَرُدُّ أُمُورَنَا إِلَى اللَّهِ وَحَسْبُنَا اللَّهُ وَنِعْمَ الْوَكِيلُ. وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ الْعَلِىِّ الْعَظِيمِ

«Нүэминү билләәһи нәҫику билләәһи нәрудду үмүүранәә иләллааһи вә хәсбүнәллааһу вә нигъмәл-вәкиил. Вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһил-галиййил-гаҙыйим».

“Аллаһыга ышанабыз. Эшләребезне Аңа тапшырабыз. Аллаһы нинди гүзәл вәкилдер! Аңардан башка көч һәм куәт иясе юктыр”.

Риваять буенча, Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә шулай дип дога кыла торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْئَلُكَ رُؤْيَا صَالِحَةً صَادِقَةً غَيْرَ كَاذِبَةٍ نَافِعَةً غَيْرَ ضَارَّةٍ

«Аллааһүммә иннии әс-әлүкә руәйә саалихәтән саадикатән гайра кәәҙибәтин нәәфигатән гайра даарратин».

“Аллаһым! Синнән салих, тугры, дөрес, ялгансыз, файдалы һәм зарарсыз төш күрүне сорыйм”.

## Иртән иртүк тору өчен укыла торган дога

Иртән иртүк тору яки кирәк булган сәгатьләрдә уяну өчен өч мәртәбә «Аятел-Көрси» укыганнан соң өч мәртәбә “Кәүсәр” сүрәсе укылыр. Аның артыннан түбәндәге доганы укырга кирәк:

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ. لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ. اللَّهُمَّ سَهِّرْ عَيْنِى وَنَوِّرْ قَلْبِى وَادْفَعْ عَنِّى كَثْرَةَ النَّوْمِ وَغِلْظَةَ الْقَلْبِ

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Ләә тәэхуҙүһү синәтүв-вә ләә нәүүм. Аллааһүммә сәһһир гайнии вә нәввир кальбии вәдфәгъ ганнии кәсратән-нәүми вә гыйльҙатәлкальби».

“Рахмән һәм Рахим булган Аллаһының исеме белән. Аны йокы да, йокымсырау да ала алмый. Аллаһым! Күзләремне уят, йөрәгемне, күңелемне яктырт, миңа йокыны күп бирмә, гафләттән коткар, Аллаһым!”

Сәхифәне **АЙСЫЛУ ЮЛДАШЕВА** әзерләде


Фото: shutterstock.com

## Рөстәм Миңнеханов:

# "Казан – мөселман дөньясында беренче басма Коръән басылган шәһәр"





Фотолар ТР Президенты матбугат хезмәтеннән

24 нче ноябрьдә Җиддә шәһәрендә «Рәсәй – ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең пленар утырышы ачылды. Утырышның көн тәртибе «Рәсәй – ислам дөньясы: диалог һәм хезмәттәшлек перспективалары» темасына багышланган. Төркем эшендә Татарстан Президенты, «Рәсәй – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Мәртәбәле кунаклар арасында Согуд Гарәбстаны короле киңәшчесе, принц Халид Әл-Фәйсал кебек башка хөрмәтле шәхесләр бар.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, пленар утырышны ачып, катнашучыларга Рәсәй Федерациясе Президенты Владимир Путин җибәргән сәламләү хатын укыды. Рөстәм Нургали улы билгеләп үткәнчә, ил Президенты мөселман илләре белән багланышларга зур игътибар бирә һәм 2005 елда Рәсәй нәкъ менә РФ Президенты инициативасы белән Ислам хезмәттәшлеге оешмасында күзәтүче булды.

– Бүген безгә мөнәсәбәтләребезнең мөмкинлекләрен активрак кулланырга кирәк. Безгә терроризмга каршы көрәшне нәтиҗәле итү һәм традицион әхлакый кыйммәтләрне саклау, җәмгыятьнең социаль яктан якланмаган әгъзалары һәм милли азчылыклар турында кайгырту, табигый һәм техноген катастрофаларга каршы көрәш, экология кебек юнәлешләр буенча үзара бәйләнешне бергәләп арттырырга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул, Татарстанны мисалга китереп: "Халыклар һәм диннәрнең гармонияле яшәеше һәм үзара хезмәттәшлегенә корылган Татарстан моделе бүген илкүләм иминлек һәм РФнең алга таба үсеш стратегиясе мәсьәләләрендә акыллы алым үрнәге буларак күрсәтелә", – дип билгеләп үтте. Татарстан Президенты үз чыгышында аерым игътибарны Идел буе Болгарстаны тарафыннан Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына да юнәлтте.

"Рәсәй – ислам дөньясы" стратегик караш төркеме утырышы барышында Рөстәм Миңнеханов 1803 елны мөселманнар әзерләгән беренче басма Коръән нәшер ителү истәлекле елы итеп билгеләү, шулай ук Казанны «Мөселман дөньясында беренче басма Коръән басылган шәһәр» дип игълан итү башлангычы белән чыкты. Шулай ук ул искә төшергәнчә, нәкъ менә Казанда 1803 елда мөселман типографиясендә Коръән беренче тапкыр массакүләм басылды.

Исегезгә төшерәбез, Нәзарәттә махсус эшләнгән "Казан басма" дизайнлы компьютер шрифты нигезендә Коръән басмага әзерләнә. "Казан басма" исемле дизайнлы компьютер шрифты дөньякүләм танылган иске типографик оттискысы нигезендә ясалды. Шрифт Коръән мөсхәфләрен бастыруга яңа зур мөмкинлекләр ачачак, Коръән һәм китаплар бастыруның татар традицияләрен яңартуга һәм үстерүгә ярдәм итәчәк.

"Казан басмасы" мөселманнар чыгарган беренче басма Коръән булып тора: ул 1803 елда Казанда Азия типографиясендә дөнья күрә. Басма өчен уникаль шрифт әзерләнгән була, шул сәбәпле Казанда басылган Коръән дөньякүләм танылу ала. "Казан басмасы" бик күп тапкырлар басылып чыкан, әмма галимнәр арасында басмада җибәрелгән хаталар турындагы бәхәсләр булган. 1909 елда Казанда "Казан басмасы"ның кимчелекләрен тикшерү өчен 300 мөселман галиме катнашында махсус фәнни җыелыш була. Аның эшендә Әхмәдһади Максуди, Шәйхелислам Хәмиди, Муса Бигиев һәм башка танылган дин белгечләре дә катнаша, әмма төрле сәбәпләр аркасында "Казан басмасы" кабаттан бастырылмыйча кала. Әлеге проектны тормышка ашыруга Татарстан мөфтияте Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына әзерлек кысаларында алына.

■ dumrt.ru сайтыннан

# Үрмәкүч үз исеме белән аталган сүрәне аңлата



Фото: shutterstock.com

"Мин кечкенә генә үрмәкүч. Әмма Аллаһы Тәгалә Коръәндә мине искә алган һәм 29 нчы сүрә минем исем белән аталган. Бу сүрә 69 аятьтән тора. Анда Аллаһы Тәгаләгә ышану, ата-ананы тыңлау, ярамаган гамәлләр кылган очракта нәрсә булачагы хакында әйтелгән. Шулай ук бу сүрәдә иман китереп, изге гамәлләр кылучыларны әҗер-саваплар көтүе һәм намаз гыйбадәтенең начар гамәллләрдән тыеп торуы хакында сүз бара. Биредә Аллаһыны зикер кылуның олуг гыйбадәт булуы, әмма гафләттә йөрүче кешеләрнең зикергә дә, догага да салкын караулары турында сүз бара. "Үрмәкүч" сүрәсендә барлык мәхлүкъларның да җир йөзендә вакытлыча гына булуы, ялганлауның начар гамәл икәнлеге һәм һәркемнән гөнаһлары өчен җавап алыначагы турында да хәбәр ителгән. Бу сүрәдә пәйгамбәрләр: Нух, Ибраһим, Лут, Шогаеб, Һуд галәйһимуссәлам хакында кыйссалар китерелә.

Нигә сүрә "Үрмәкүч" дип аталган соң? Сәбәбе 41 нче аятьтә. Монда үрмәкүч үргән пәрәвезләрнең зәгыйфь һәм ышанычсыз булуы турында искә алынган. Әмма бу пәрәвезләр безнең өчен бик көчле һәм нык булып күренә. Кешеләр безнең аны үрер алдыннан математик һәм геометрик яктан исәпләгәнне белми дә. Үргән пәрәвезебез безнең өчен йоклар урыныбыз да, куркынычлардан саклый торган җиребез дә булып хезмәт итә. Әмма безгә нык булып тоелган пәрәвезебез безне салкыннардан сакламый, күләгә ролен үтәми. Җил исеп китсә йә берәрсе сак кына кагылса да – ул җимерелә.

Бу сүрә исеменең үз хикмәте бар: үрмәкүчнең пәрәвезе ышанычсыз булган кебек, Аллаһыдан башкага ышанучының, тәвәккәл итүченең дә тереге ышанычсыз. Кешеләр еш кына үзләре өстенлек биргән кыйммәтләрне олуглый һәм аңа зур әһәмият бирә. Күпләр үзләренең көчле булулары бай, дәрәҗәле булуда дип уйлап ялгыша. Шуңа күрә гомерен болар артыннан куып уздыра. Кайберәүләр вакытын файдасыз гыйлемгә исраф итә, ә икенчеләр көчне тән ягыннан нык булуда гына күрә. Әмма хакыйкый көч – Аллаһыдадыр, чөнки Ул һәрнәрсәнең Яратучысы.

Аллаһы Тәгалә бу ялгышуларны үрмәкүч пәрәвезе белән чагыштыра: бераз гына җил исеп куйса, йә берәрсе кагылып үтсә – җимереләчәк. Хакыйкый көч – Аллаһы Тәгаләнең ярдәмендә, рәхмәтендә булуда, чөнки әгәр Ул теләсә, черки кебек кечкенә генә бөҗәк тә Нәмруд кебек патшаны юк итә ала һәм хәтта гап-гади пәрәвез дә коралланып килгән кешеләрне адаштырырга мөмкин. Беләсез: Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дусты Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән бергә тау куышлыгында булганда, аларны куып килүче кешеләр нәкъ менә шул пәрәвезгә алданды. Беләсегез килсә, ул көнне Галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән Расүл һәм аның дусты белән булган үрмәкүч – ул мин идем. Бу минем гомеремдәге иң яхшы көн булды. Мин, Аллаһының рәхмәте белән, бик мөһим вазифаны башкара алдым. Расүлебез дусты Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән, дошманнарыннан котылганнан соң, Мәдинә шәһәренә сәфәрләрен дәвам иттеләр.

Кадерле дусларым! Беркайчан да Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, беркайчан да Аннан ярдәм сораудан туктамагыз. Менә күрерсез, әгәр Ул теләсә, рәхмәтен индерсә, хәтта пәрәвез кебек җепләр дә сезне саклап калуда ярдәм итә ала.

■ Сәхифәне
**Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде





## *"Хозур" нәшрият йорты "Тимергали хәзрәт вәгазьләре" китабын нәшер итте*

Динебездә башкаларны күркәм сүз белән нәсыйхәтләүгә, аларга Коръәни Кәримебез аятьләрен, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрен искә төшерүгә зур әһәмият бирелә. Нәсыйхәт, вәгазь күңелләрне нур белән тутыра, кешенең Аллаһыга якынаюына, әхлагын камилләштерүенә сәбәпче булып тора. ТР МДНнең "Хозур" нәшрият йорты тарафыннан нәшер ителгән "Тимергали хәзрәт вәгазьләре" китабы да әлеге максатларны күз алдында тотып әзерләнде. Биредә хәзрәтнең төрле темаларга кагылышлы вәгазьләре урын алган. Китапта Рамазан ае, корбан чалу фазыйләтләре, ата-ана хакы, гыйлем алу мөһимлеге, төрле кыйссалар, һәм гомумән, кешене рухи яктан баета торган вәгазьләр белән таныша алабыз. «Тимергали хәзрәт вәгазьләре» китабы киң катлау укучылары өчен тәкъдим ителә. Китап һәркем өчен дә файдалы булыр дигән өметтә калабыз.

Китапны "Хозур" нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.

**Кибет:** Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63;
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru

12+

# Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать гакыйдәсе

*Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать гакыйдәсе – традицион Ислам инде ул. Ул – уттан котылганнарның карашлары, ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләр, сәләфләр һәм Кыяматкә кадәр аларга ияргән галимнәрнең карашлары.*

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

50. Бу өммәттә Пәйгамбәребездән соң иң хәерле кеше – Әбү Бәкер, аңардан соң Гомәр, Госман, аннан – Гали. Бу хәлифәләрнең хакимлеге рас һәм Пәйгамбәребезнең Сөннәтенә туры килә.

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать вәкилләре бу тугры хәлифәләрнең Пәйгамбәребез вафатыннан соң хакимлекләре тәртибенчә, сәхабәләр арасында иң өстеннәре булуларын таныйлар.

51. Без Пәйгамбәребезнең сәхабәләре турында бары күркәм сүзләр генә сөйлибез.

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать вәкилләре сәхабәләр арасында булган сәяси каршылыкларга кермиләр, бу каршылыклар бары изге ниятттән генә килеп чыгуына һәм һәр сәхабәнең хакны эзләүдә куйган көче өчен үз әҗерен алуына ышаналар. Без алар хакында иң яхшы фикердә.

52. Без беренче буын тәкъва (сәләф) мөселманнар арасыннан булган имам Әбү Хәнифә, имам Мәлик, имам Шәфигый һәм имам Әхмәд шикеллеләрен яратабыз һәм хөрмәт итәбез. Иҗтиһад дәрәҗәсенә ирешмәгән һәрбер мөселманның әлеге дүрт имам мәзһәбенең берсенә иярүен тиеш саныйбыз, чөнки башка имамнарның мәзһәбләре сакланмаган һәм безгә тулысынча ирешмәгән.

Әһле Сөннәт һәм Җәмәгать мөселманнары Коръән һәм Сөннәтне беренче буын галимнәре (сәләфләр) аңлаганча аңлату кирәк дип саныйлар. Шунлыктан алар менә инде ун гасыр буенча дүрт мәзһәбнең берсенә ияраләр, чөнки Коръән һәм Сөннәтне мөстәкыйль рәвештә аңлый алмаган кеше гыйлемле кеше артыннан ияреtogether тиеш, ә алда китерелгән дүрт имам – шул гыйлемлеләрнең иң яхшылары. Алар – сәләф галимнәре арасында булган, фикһлары сакланып, олы галимнәр аша чылбыры өзелексез хәлдә безнең көннәргә хәтле килеп җиткән имамнар. Шуның өчен дә, алар мәзһәбенең урынын алырдай мәзһәб юк.

53. Коръән һәм хәдисләргә бары мөҗтәһид, ягъни шәригать гыйлемнәренең иң югары дәрәҗәсенә ирешкән шәхес кенә мөстәкыйль рәвештә аңлатма бирә ала. Бу дәрәҗәгә ирешмәгән башка шәхесләр мөкаллид булып санала, ягъни мөҗтәһид имамга ияреregә тиеш.

Бүгенге чорның яңалыгы – мәзһәбсезлек, Коръән һәм Сөннәтне гыйлеме булмаганнар аңлатырга алынган чор.

54. Без күн читекләргә мәсех кылуны динебез тарафыннан рөхсәт ителгән дип саныйбыз, ләкин гади оекбашка мәсех кылу рөхсәт ителмәгән.

Дүрт мәзһәбнең дә имамнары фикеренчә, хәзерге оекбашлар мәсех таләпләренә туры килмиләр. Элеккеге имамнар күн оекбашлар турында язганнар, чөнки күн оекбашларга мәсех тарту ярамый диюче төркемнәр булган. Ә безнең чорда гади оекбашка мәсех тартырга ярый диюче төркемнәр барлыкка килде. Шунлыктан, бу тема гакыйдә бүлегендә искә алына.

55. Асылда, Коръән һәм Сөннәтне, мөмкин булганча, сүзгә-сүз аңлау кирәк. Сөннәт – ул Коръәнне аңлата торган вәхи булып тора. Сөннәттән башка Коръәнне аңлау мөмкин түгел. Сөннәтнең шәригать чыганагы булуын инкяр итүче имансыз санала.

Көферлекнең бер төре – хәмернең тыелганлыгы, намаз турындагы мәгънәләре ачык аңлаешлы аятьләрне, туры мәгънәләрен кире кагып, күчерелмә мәгънәдә аңлату. Сөннәтне шәригатьнең чыганагы булуын инкяр итүчеләр Пәйгамбәребез артыннан ияру кирәклеген ачыктан-ачык әйткән аятьләрне дә кире кагалар.

56. Без Коръән һәм хәдисләрнең төп өлеше безгә үзгәрешсез иреште, дип саныйбыз. Кем хәдис китаплары үзгәртелгән дип саный, ул кинаяле рәвештә Коръәнне дә үзгәртелгән дип кабул итә; чөнки Коръәнне дә, Сөннәтне дә бер үк кешеләр ирештергән.

Барлык мөселманнар Коръән Аллаһы Тәгалә тарафыннан Пәйгамбәребезгә вәхи рәвешендә иңдерелгән, тулы һәм үзгәрешсез хәлдә сакланып, мөселманнар риваять иткән китапларда язылган дип саныйлар. Коръәннән бернәрсә дә җуелмаган (югалмаган), аңа бернәрсә дә өстәлмәгән, киресенчә уйлаучылар мөэмин-мөселман түгел.

Коръәнне саклауның бер шарты – аның аңлатмасының да саклануы, димәк, Сөннәт тә саклана. Галимнәр арасында кайбер хәдисләрнең дәреслеге хакында фикер каршылыклары туарга мөмкин, әмма кем Сөннәт сакланмаган, югалган яисә уйлап чыгарылган дип саный, шул кяфер була, чөнки ул Коръәнне аңлау мөмкинлеге беткәнен исбатларга тырыша.

57. Шәригатьнең шөбһәсез хөкемнәрен кире кагучы – имансыз. Мәсәлән, зинаны хәләл итүче – шундыйлардан.

Иманның шарты – Пәйгамбәребез диннең бер өлеше итеп ирештергәнне һәм диннән шөбһәсез беленгәннәрне хакыйкать итеп кабул итү. Мәсәлән, бер җирлектә яшәгән халык, үзләренең гыйлемсезлеге аркасында, берәр дини тәгълиматны белмиләр икән, бу тәгълиматны кире кагулары көферлек булмый.

58. Аллаһы колларының догаларын кабул итә һәм теләкләрен үти. Үлгәннәр өчен кылынган дога һәм бирелгән садакалар аларга ирешә һәм файда китерә.

59. Коръән укып, аның савабын үлгән мөселманга багышларга мөмкин. Кеше үзенең изге эшләренең савабын да үлгән мөселманнар рухына багышлый ала.

Имам Әбү Хәнифә фикеренчә, барлык изге гамәлләргә, Коръән уку булсынмы, садака бирү булсынмы, бирелгән әҗер савапларны үлгәннәр рухына да багышлап була, исәннәргә дә атап була.

60. Без сихернең барлыгына ышанабыз, әмма аның белән шөгыльләнү Исламда тыелган. Сихерчеләргә мөрәҗәгать итү шулай ук катгый тыелган. Без сихерчеләрнең, күрәзәчеләрнең сүзләренә, йолдызнамәләргә (гороскопларга) ышанмыйбыз. Кеше тормышында булган вакыйгалар планеталар хәрәкәте белән билгеләнми – алар Аллаһы тарафыннан тәкъдир ителгән.

Сихерчелек – зур гөнаһ, әгәр уйлап табылган илаһларга мөрәҗәгать итүне эченә алган мәҗүсилек төсмерен дә алса, ул көферлеккә чыгара. Кешенең яшәешен һәм холкын планеталарның торышы яисә туган көне түгел, ә Аллаһы билгели. Ә йолдызнамәләр – ул күрәзәчелекнең бер төре, аларга ышанырга ярамый.

## Йомгак

Без өстебезгә, май аенда яуган яңгыр кебек, ялган идеология ишелеп төшкән чорда яшибез. Бу куркыныч дәвердә без Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, безне туры юлга күндерүен, иманыбызның көчен ныгытуын сорыйбыз. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**"[Ий Расүлем һәм сәхабәләр!] Инде әгәр алар [яһүдиләр һәм насаралар] сез иман китергән нәрсәләргә сезнең кебек иман китерсәләр, һичшиксез, алар туры юлны тапкан булырлар".**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:137

Йә Раббым! Безгә беренче мөселманнар – Пәйгамбәребезнең сәхабәләренеке кебек иман һәм ышаныч бир, безне туры юлдан тайпылдырма һәм адашулардан сакла! Әмин!

■ Мөфти **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**



Фото: shutterstock.com



●*Габдерәшит Ибраһимов (1857-1944).*
Фото **facebook.com** сайтыннан алынды

# “Коръәнне яттан өйрәнү җиңел, аннары хәтердә саклау кыен”




Габдерәшит Ибраһимов XIX гасыр ахыры – XX гасырның беренче яртысында Рәсәйдә яшәгән иң күренекле мөселман эшлеклеләренең берсе була. Ул үзенең киң эшчәнлек алып баруы һәм сәяхәт кылулары белән, Рәсәйдә генә түгел, бөтен мөселман дөньясында танылa. Габдерәшит Ибраһимов Уфадагы Ырынбур мөселман Диния нәзарәтендә казый вазифасын башкарганга күрә, мөселманнар арасында Габдерәшит казый буларак билгеле.

Соңгы елларын Габдерәшит казый Токиода үткәрә. Биредә ул татар җәмәгатьчелегенең дини башлыгы була.

Габдерәшит Ибраһимов 1857 елда, хәзер Омск өлкәсенә кергән, Тара шәһәрендә туган. Аны нәселе Бохара ханлыгыннан булган ата-бабаларга барып тоташа, әмма үзен ул татар яки Себер татары дип атарга күнеккән була. Башлангыч белемне Габдерәшит Ибраһимов туган якларында алган. Ә 1877 елда, данлыклы Кышкар мәдрәсәсендә (бүгенге көндә ТРның Арча районындагы Кышкар авылы) уку нияте белән, Казан губерниясенә килә. Әмма анда ул ел ярым гына укый: яңа паспорт алыр өчен аңа туган ягына кайтып китәргә кирәк була.

1878 елда Габдерәшит Ибраһимов тирән гыйлемнәр туплау өчен Мәдинә шәһәренә китәргә карар кыла. Ул вакытта 21 яшьлек егет Акмола өлкәсендә бай казахлыларның балаларын укыту белән шөгыльләнә. Сәфәргә чыгу эшендә аңа хәлле казах кешесе – Умар Волость ярдәм итә. Ул аңа сәфәргә чыгу өчен 150 сум акча бирә.




Габдерәшит Ибраһимовның Мәккә һәм Мәдинәгә сәфәре җиңел булмый. Хиҗазга килеп җитәр өчен аңа шактый кыенлыклар аша үтәргә туры килә. Ул изге җирләргә хаҗилар белән бергә барырга карар кыла. Ул вакытларда хаҗга ике юл белән барганнар: беренчесе – элеккеге юл һәм ул күп очракта коры җир аша үткән. Бу юл Бохара һәм Һиндстан аша узган. Икенче юл диңгез аша булган. Ул Одесса һәм Стамбул шәһәрләре аша үткән.

Габдерәшит Ибраһимов икенче юлны сайлаган. Баштан ул Түбән Новгородка килеп җиткән, аннары поездда Мәскәү аша Одессага юл тоткан. Ерак сәфәргә чыгуда тәҗрибәсез булганга күрә, ул үзе белән аз акча алган. Одесса шәһәрендә бары тик 30 сум акчасы гына калган. Одессадан Җиддә шәһәренә (Согуд Гарәбстаны) килеп җитү өчен чама белән 150-300 сум акча (сәфәрнең уңайлылыгына карап) кирәк була. Одессада бер көн торып, ул булган барлык акчасын тотып бетерә.

Нәтиҗәдә, мәрмәр ваннада яшеренеп, Стамбулга юл тота торган Итальян корабына эләгү бәхетенә ирешә. Юлда аның бер тиен акчасы да калмый. Әмма, бәхеткә, чыгышы белән Идел буеннан булган, Стамбулда яшәүче Мөхәммәдрәхим әфәнде ярдәме белән, күпмедер вакытка Госманлы империясендә яшәп тору мөмкинлегенә ия була. Аннары аңа Иркутск шәһәреннән булган татар сәүдәгәре Хисаметдин бай акчалата ярдәм итә. Җиддә шәһәренә бара торган пароходка билет алганнан соң, алар бергәләп изге җирләргә юл тоталар. Хаҗ сәфәре төгәлләнгәч, Габдерәшит Ибраһимов Мәдинә шәһәренә укырга китә.

Бу җирләрдәге беренче Рамазан ае яшь шәкерткә бик нык тәэсир ясый. Аны бу изге көннәрдә Мәдинә халкының хәтем (Коръәнне тулысынча укып чыгу) һәм тиләвәт (Коръәнне матур итеп уку) кылулары соклandыра. Ә Гомәр Заһид исемле бер имам Коръәни Кәримне бер төн эчендә укып чыга алган.

Шул сәбәпле, Габдерәшит Ибраһимов Коръән-хафиз булырга, ягъни Коръәни Кәримне тулысынча ятларга ният кыла. Бу хакта ул шәехләрнең берсе белән киңәшләшә һәм ул аңа мондый сүзләр әйтә: “Коръәнне тулысынча ятлау җиңел, әмма аннары үзгәрешсез хәлдә хәтердә саклау кыен”.

Ул Габдерәшит Ибраһимовка берничә тапкыр истихара намазын укырга киңәш итә. Нәтиҗәдә, Габдерәшит Ибраһимов һиҗри ел исәбе буенча 1298 елның 1 нче мөхәррам аенда (1880 елның 3 нче декабре), Мәдинә шәһәрендәге “Әмин Ага” дип исемләнгән мәдрәсәгә укырга керә. Шул рәвешле, Мәдинәдәге беренче Рамазан ае яшь Габдерәшит Ибраһимовны олуг эшкә – Коръәни Кәримне ятлауга этәргәч була.

■ **Дамир ГАЙНЕТДИНОВ** язмасы,
**islam-today.ru** сайтыннан тәрҗемә

# Дога тәкъдирне дә үзгәртә

***Дога – ул гарәп теленнән мөрәҗәгать итү, сорау дип тәрҗемә ителә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дога – ул бәлаләрдән саклый, хәтта кешенең тәкъдирен дә үзгәртә ала», – диде. Пәйгамбәрнең сәхабәсе Ибне Гомәрнең: «Аллаһым, әгәр мине бәхетсез итеп, исемемне бәхетсезләр дәфтәренә язган булсаң, аны сөртеп юк итсәң һәм бәхетлеләр дәфтәренә язсаң иде. Әгәр бәхетлеләрдән итеп, исемемне бәхетлеләр дәфтәренә язган булсаң, бу язуны беркайчан да сөртелми торган ит», – дип дога кылуы билгеле.***


Фото: shutterstock.com

Даими рәвештә дога кылган кеше беркайчан да үзен ялгыз итеп тоймас, чөнки Аллаһы кешенең догасын җавапсыз калдырмый. Әмма дога кабул булуының шартлары бар.

Беренче шарт: хәләл ризык белән туклану, хәләл кием кию һәм хәләл кәсеп белән шөгыльләнү.

Икенче шарт: доганың кабул булуы өчен ихласлык кирәк. Сорагынымны Аллаһы кабул итәрме-юкмы икән дип шикләнергә ярамый.

Өченче шарт: өмет һәм сабырлык белән дога кылу. Булса – була, булмаса – юк, дип торсаң, әлбәттә, кабул булмый, ихластан, өметләнеп сорасаң, чынга ашу ихтималы да арта. Ашыгу да дөрес түгел. Аллаһы Тәгалә: «Кешеләрнең төп хатасы – ашыктырулары», – дип әйтә.

Дога кылуның аерым бер вакыты бар, дип аерып кую бик үк дөрес булмас, кеше Аллаһыга теләсә кайчан мөрәҗәгать итә ала. Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, доганың кабул булу ихтималы зур булган вакыт – ул төнге намаз – тәһәҗҗед вакытында, дигән. Төнге намазны укыганнан соң дога кылсаң, ул, һичшиксез, кабул булачак. Тагын бер хикмәтле вакыт – кояш чыккач укыла торган ишракъ намазы вакытында. Шулай ук һәрбер фарыз намазыннан соң да дога кылырга тырышыгыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җомга көнне дога кабул була торган яшерен бер вакыт бар», – дигән. Бу, изге җомга көнендә кеше күбрәк догада булсын өчен, махсус кайсы вакытта икәне төгәл әйтелми.

Дога кабул була торган урыннар да бар. Өч төрле кеше Аллаһының кунагы булып санала. Шуның берсе – хаҗга баручы. Нинди сәгатьтә дога кылса да, аның догасы кабул була. Хаҗда дога кабул була торган урыннар күп. Чыннан да, Кәгъбәтулланың ишеге тирәсендә аерым бер көчле энергетика сизелә. Кешеләр Кәгъбәтуллага куллары белән тотынып дога кыла. Пәйгамбәребезнең хәдисендә дә, нәкъ шушы урында догалар кабул була, дип әйтелә. Тәваф вакытында, Зәм-зәм суын эчкәндә, Сафа белән Мәрва арасында йөгергән вакытта, мәкам Ибраһим дип атала торган җирдә, ягъни Ибраһим пәйгамбәрнең Кәгъбәне төзегәндә таштa калган аяк эзләре урынында, Гарәфәт тавында, Мина һәм Мөздәлифә үзәнлегендә, һичшиксез, дога кабул була.

Күпләребез, әбиләребезнең яңгыр яуганда теләк кабул була, теләк теләгез, дога кылыгыз, дигәнен ишеткәне бардыр. Әйе, бу, чыннан да шулай, чөнки яңгыр – ул Аллаһының рәхмәте. Ә Раббыбызның рәхмәте иңгән вакытта догалар кабул була.

Шуңа күрә яңгыр яуган вакытта, төнлә тәһәҗҗед намазына уянганда догалар кылу бик тә дөрес гамәл. Кешенең төп максаты – дога кылу һәм шуның белән ул Аллаһыга якынаю. Кеше моннан файдалансын, Аллаһыны искә төшерсен, аңа зикер кылсын. Бөтенләй дога кылмаганга караганда, бу әйбәтрәк, билгеле. Шуның белән, бәлки, кешедә даими рәвештә дога кылу теләге туар, дингә тагын да якынаер.

Кайвакытта кешеләр, бөтен шартларын җиткереп дога кылдым, әмма кабул булмады, дип әйтә. Шунысын да белеп торыйк: Аллаһы Тәгалә адәм баласының догасын йә шунда ук яки бераз соңрак кабул итә, йә Ахирәткә калдыра, йә булмаса шуның өчен берәр бәладән коткара.

Бу дөньяда кабул кылынмыйча, Ахирәткә калдырылган догалар турында хәдисләрдә болай дип әйтелә: кеше кабердән кубарылып, Аллаһы каршына килгәч, тау кадәр өелгән зур саваплар күрәчәк һәм, йә Раббым, мин бит әллә нәрсә эшләмәдем дә, бу саваплар каян килгән, дип сорар. Аңа: «Бу – синең дөньяда кабул кылынмаган догаларың», – дип әйтерләр. Һәм ул: «Раббым, бөтен догаларымны да кабул итмәгән, Ахирәткә күчергән булсаң иде», – дип әйтер. Без үзебез өчен нәрсә хәерлерәк булуын белмибез.

Кайбер кеше дога кылуны мәчеткә яки берәр әби-бабайга садакасын биреп башкарта. Әмма үзең дога кылсаң, тагын да хәерлерәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең догасы кабул булу ихтималы күбрәк дип, кешеләр аңа барган. Хәзер аның варислары – дин галимнәре, әүлияләр бар. Алар Пәйгамбәребез үрнәгендә сөннәт буенча яшәргә тырыша. Әүлияләр бүген бик аз. Булсалар да, без аларны белмибез, чөнки моны әйтеп йөрмиләр. Дин галиме – ул гыйлеме белән гамәл кылучы кеше. Аллаһы Коръәндә, иманлы бәндәләр сөйләгән сүзләрен үзләре үтәргә тиешлегенә басым ясый. Коръәндә:

**«Эшләмәячәк нәрсәләрне сөйләвегезгә Аллаһының ачуы [һәм нәфрәте] бик зур»**, – дип әйтелгән.

«Әс-Сафф / Саф», 61:3

### Дога белән дәвалану

Белеп торыйк: Аллаһыдан хәерле эш, гыйлем сорап дога кылу бер нәрсә, аңа ирешү өчен кеше үзе дә тырышырга тиеш. Пәйгамбәребез башта дога кыла, аннары даруын каба иде. Башта шифаны Аллаһыдан сорарга кирәк. Аллаһы әмере булмаса, яфрак та селкенми. Ул безгә авыруын да, шифасын да җибәрә.

Дога белән дәвалану очраклары турында да ишетеп беләсездер. Күп гасырлар элек атаклы галим Әбүгалисина: «Авыруны дәвалауда өч төрле чара бар: сүз, үлән һәм пычак», – дип әйткән. Әйе, хәзер инде теләсә кайсы әгъзага операция ясап, кешене үлем тырнагыннан тартып алып калулар да гадәти күренеш. Медицина төрле үләннәр ярдәмендә дарулар җитештерә, ә халык медицинасы ул үсемлекләрнең үзен генә куллануда да искиткеч могҗизаларга ирештерә. Сүз, ягъни Коръән аятьләре белән дәвалану да бар әле.

Догаларның авыруларны дәвалауга ярдәме зур булуын бүгенге заман галимнәре дә исбат итте. Безнең ата-бабаларыбыздан калган «өшкерү»ләр дә әнә шул рәвешле дәвалауның дәлиле булып тора түгелмени?!

Кызганычка, без бүген Изге Китапның илаһи көче хакында белеп кенә бетермибез. Ә анда болай дип әйтелгән:

**«Без мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәт булган Коръәнне индерәбез. Әмма ул [Коръәни Кәримне инкяр итүдә үҗәтлек күрсәткән] залимнәргә зарардан башка берни дә арттырмый».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:82

Традицион медицина кешеләргә ярдәм итә алмаган чакларда да, Коръән аятьләре белән дәвалана алу очраклары хакында күп мисаллар китерергә була. Әйтик, «Фатиха» сүрәсендә һәр авыруга шифа бар. Аны көненә 100 тапкыр укысаң, шифасын да табарсың. Галимнәр әйтүенчә, иртәнге намаздан соң 40 көн буена 41 тапкыр «Фатиха» сүрәсен укысаң – догаң кабул була. Ләкин Коръән белән дәвалану өчен, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм Коръәнгә ышанырга кирәк.

### Дога кылу тәртибе

Дога кылу тәртибенә килгәндә, доганы Аллаһы Тәгаләгә хәмед һәм сәна, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтүдән башлыйлар. Кешенең тәһарәтле булуы хәерле. Кыйбла тарафына юнәлеп, доганы әчтән, тыныч кына, курку һәм өмет белән уку дөрес. Күңелдән чыккан ихлас сүзләр генә әйтелергә тиеш. Расүлебез Мөхәммәд рухына, атабыз Адәм галәйһиссәлам һәм анабыз Хәввадан алып, бүгенге көнгә кадәр килгән бөтен пәйгамбәрләрнең, әүлияләрнең, галимнәрнең рухларына, аннары әти-әниләргә, шуннан соң гына үзең һәм балаларың өчен сорыйсың.

Әмма кайбер кеше вафат булган әти-әниләреннән ярдәм сорый. Бу дөрес гамәл түгел. Мәетләр үзләре безнең догага мохтаҗ. Алар безгә берничек тә ярдәм итә алмый. Тере кешенең төп өстенлеге – аның исән булуы. Бер кеше кабер янында дога кылып утырган җирендә йоклап киткән һәм төшендә шул кабердә җирләнгән кардәшен күргән. Кабердә ятучы кеше аңа: «Мин синнән көнләшәм, синең гамәл кылырга мөмкинлегең бар, әмма Ахирәт турында гыйлемең юк, ә минем, киресенчә, гыйлемем бар, ләкин гамәл кыла алмыйм. Ике рәкәгать укыган намазың, кылган догаң өчен нинди зур әҗерләр бирелүен белсәң, даими тырышлык куяр идең», – дигән. Бу дөнья – исән булган вакытыбызда изге гамәлләрне туплый торган вакыт ул. Шуларны белеп торыйк.

Аллаһы Раббыбыз ике дөнья бәхетенә ирешеп, кылган догаларыбызның кабул булуын һәм хата-кимчелекләрдән ерак булуыбызны насыйп әйләсә иде.

■ **"Тимергали хәзрәт вәгазьләре"** китабыннан



# АНА ХАКЫ

Фото: shutterstock.com

Әни... Бу сүзгә күпме җылылык, ярату, наз салынган. Әни кешенең кадерен, үзең әни булгач кына белеп була, дигәннәр. Раббыбыз хатын-кызны шулхәтле олылап, аңа зур дәрәҗә биреп, әни дигән исемгә лаек иткән. Әни – ул кайгыртучы да, яратучы да, назлаучы да, яклаучы да, кирәк вакытта аеруча да игътибарлы булып, безгә адашмас өчен туры юл күрсәтүче дә, барысын да үз йөрәге аша тоеп: "Балам бәхетле булса иде", – дип, һәрдаим өзгәләнеп яшәүче дә... Әни кешенең хакларын үтәп бетерү мөмкин түгел. Берьюлы Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе әнисен аркасына күтәреп, Кәгъбәтулла тирәли тәваф кылучы ирне күргән. Аның йөзендә бернинди дә авырлык тою, арганлык хисләре чагылмаган. Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһегә карап, ул: "Мин әнием алдындагы бурычымны үтәдемме?"– дип сораган. Сәхабә: "Юк, синең тырышлыкларыңны аның сине тудырганда кичергән авыртулары белән чагыштырып та булмый", – дип җавап биргән.

## Җәннәт әниләрнең аяк табаны астында

"Җәннәт әниләрнең аяк табаны астында" – дигән хәдисне барыбызның да ишеткәне бардыр. Бу хәдис әни кешенең никадәр олуг, хөрмәткә лаек кеше икәнен аңлата. Аның мәгънәсе бик тирән. Һәрбер мөэмин-мөселман кешесе Раббыбызның ризалыгына ирешергә, җәннәтле булырга тели. Бу юл үз-үзеңне тәрбияләүдән, нәфесләреңне җиңүдән, холкыңны камилләштерүдән гыйбарәт. Күркәм холыклы, изге гамәл-гыйбадәтле булып, Раббысыннан куркып гомер итүче кеше генә Аллаһының рәхмәтенә ирешүнең нинди зур дәрәҗә икәнен аңлый. Һәм бу юлда тагын бер мөһим вазифабыз бар – ул ата-ана хакын үтәү. Юкка гына Расүлебез: "Аллаһы ризалыгы ата-ана ризалыгында, ә Аның ачуы ата-ана ачуында", – дип әйтмәгән (Имамнар Әл-Бохари, Әт-Тирмизи, Ибне Хиббән риваять итә). Димәк, ата-анасының ризалыгын алмаган, Аллаһым сакласын, аларны рәнҗетеп яшәгән кеше Раббыбыбызның риза булуына өметләнә аламы?! Һәркем бу сорауга үзе җавап бирсен.

## Ана кешенең бөеклеге

Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

**"Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә. [Боларның барысы өчен дә, иң элек, Яратучың буларак] Миңа һәм [шуннан соң барлыклар арасыннан яратылыш сәбәбең булган] ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа [булачак]",** – дип әйткән.

«Локман», 31:14

Берьюлы Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына берәү килеп: "Йә Расүлуллаһ! Мин иң беренче булып кемгә яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш?" – дип сораган. Расүлебез: "Әниеңә" – дип җавап биргән. Тегe кеше: "Ә аннары кемгә?" – дип сораган. Расүлебез кабат: "Әниеңә", – дип җавап кайтарган. Тегe кеше тагын: "Ә аннары?" – дигән. Расүлебез монысында да: "Әниеңә", – дигән. Бу кеше тагын бер тапкыр: "Ә аннары кемгә?" – дип сорагач, бу юлы Расүлебез: "Ә аннары әтиеңә", – дип җавап кайтарган. Әти кешенең гаиләдә роле бик зур. Ул гаиләсен тәэмин итүче, яклаучы, Кыямәт көнендә гаилә әһелләре өчен җавап бирүче... Әмма Раббыбыз ана дигән бөек исемне хатын-кызга биргән. Коръәндә ана кешенең бөеклеге, аның нинди авырлыклар белән йөрәк парәсен тудыруы, йокысыз төннәрен калдырып, авырлык белән аны үстерүе хакында аять бар:

**"Анасы аны мәшәкать белән [тугыз ай карынында] йөртте һәм аны авырлык белән тудырды. Аны йөртүе һәм [имчәктән] аеруы – утыз ай"**

«Әл-Әхкаф / Ком таулары», 46:15

Әлеге аятьтән без хатын-кызның бу олы вазифаны өстенә алуы белән күпме авырлыклар аша үткәнен күрәбез. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: "Һәр төнне йөкле хатын-кыз төне буе гыйбадәттә торган һәм көне буе ураза тоткан кеше кебек савап ала", – дип әйткән. Икенче бер хәдистә: "Бала тапкан хатын-кызга 70 ел намаз укыган һәм ураза тоткан савап языла. Ә бер авыртуы өчен бер тапкыр хаҗ кылган әҗер-савапка ия була", – дип әйтелгән.

## Аллаһыга якынайта торган гамәл

Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһе, әниләргә карата булган күркәм мөнәсәбәтебез Раббыбыз белән элемтәбезне яхшыртуда мөһим урын алганын белдереп, болай дип әйткән: "Ана кешегә булган күркәм мөнәсәбәт кебек, Аллаһы Тәгаләгә якынайта торган башка гамәл күрмим" (Имам Әл-Бохари, "Әл-әдәп әл-мөфрад", 4).

Әгәр сәхабәләрнең, галимнәребезнең тормыш юлына күз салсак, аларның гамәл-гыйбадәтләре, тормыш-көнкүрешләре, холыкларының үзенчәлекләре белән танышсак – гаҗәп калырбыз. Иман, ислам нуры аларның калебләрен тулаем яктырткан булган. Шуңа да алар гамәл-гыйбадәттә дә аеруча да ихлас, тырыш булган, холыкларын күркәмләү, әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлы булуда да алга киткән һәм, әлбәттә, ата-анага хөрмәт, аларны олылап яшәүдә дә безнең өчен үрнәк булып торалар.

Ибне Могавия исемле галимнең әнисе вафат булгач, ул бик еш аны искә алып, елый торган булган. Аннан нигә шулхәтле елавы хакында сораганнар. Галим: "Элек минем җәннәткә кертә торган ике ишегем бар иде, ә хәзер аларның берсе ябылды", – дип әйткән.

## "Син дә аларга мәрхәмәт ит"

Ата-анага итагатьле булуыбыз, аларны хөрмәт итеп яшәвебез өстенә, бу кадерле кешеләребез өчен һәрдаим догада булып яшик. Әлбәттә, һәрберебез дә үз телебездә алар өчен саулык, иминлек, бәрәкәт, тигезлек сорый ала. Шулай ук Коръәндә Раббыбыз безгә әти-әниебез өчен дога кылу үрнәген дә китерә:

رَبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا

Укылышы: «Раббирхәмһүмәә кәмәә раббәйәәнии сагыйыйраа».

Мәгънәсе: **«Ий Раббым! [Минем фани мәрхәмәтем нәрсә генә ул?] Алар кечкенә чагымда мине [зур бер шәфкать белән] үстергәннәре кебек, Син дә аларга [бакый рәхмәтең белән] мәрхәмәт ит».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:24

Доганың көчен, мөһимлеген истә тотып, бу сүзләрне әйтүне күркәм гадәткә әйләндерик. Догаларыбыз белән Раббыбызның ризалыгына ирешә, ә ата-аналарыбызга карата яратуыбызны, кайгыртуыбызны белдерә алсак иде.

■ Айсылу ЮЛДАШЕВА

# ВИНОГРАД


Фото: shutterstock.com

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләмне яраткан, бик тә хөрмәт иткән мөселманнар ничек тә аның күңелен күрергә, нинди дә булса яхшылык эшләргә тырышалар иде. Бер көнне Аллаһның рәсүле сахәбәләре белән бергә утырганда, аның янына фәкыйрь кыяфәтле бер ир килә. Кулында бер савыт виноград тотып торган бу бәндә пәйгамбәрне күргәч, ничектер оялып, каушап кала, һәм килүенең максатын аңлатып:

- Әй рәсүлүллаһ! Сиңа берәр игелек эшләргә теләдем, шуңа күрә менә шушы виноградны күчтәнәч итеп алып килдем. Рәхим итеп кабул кылчы! - дип әйтә дә, калтыраган кулы белән савытны Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләм алдына куя.

Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм баш ишарәсе илә рәхмәтен белдереп, бер виноград җимешен ашап куя да, елмаеп җибәрә. Шуны күргән ир дә елмая башлый. Соңыннан пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләм икенче җимешне ашый, аннан соң өченчесен, дүртенчесен, һәм һәр җимешне йоткан саен аның йөзен нурлы елмаю яктырта иде. Шулай итеп, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм бөтен виноградны ашап бетереп, савытын кире тапшыра, ә теге ир шатлыгын йөрәгенә сыйдыра алмыйча, бөтен әйләнә-тирәне бәхетле йөзе белән яктыртып, кайтып китә. Әмма сахәбәләр бу хәлгә бик аптырап калалар, чөнки башка вакытта Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә нинди генә ризык алып килсәләр дә, ул һәрвакытта иптәшләре белән бүлешә иде. Ә бу юлы бирелгән күчтәнәчне беркемгә дә тәкъдим итмичә, үзе генә ашады... Сахәбәләрнең берсе соңрак моның сәбәбен сорагач, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм болай җавап бирде:

– Бу ир кеше алып килгән виноград бик әче булып чыкты. Әгәр мин сезнең белән бүлешкән булсам, арагыздан берегез бу хакта әйтеп, виноградны алып килгән кардәшебезнең күңелен төшерер иде. Ә болай ул өенә бик шатланып кайтып китте...

# ГАҖӘЕП КӨРӘШ

Мәгълүм булганча, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләм Мәккә шәһәрендә туып үскән. Пәйгамбәрлекнең беренче 13 еллык чоры да шул шәһәрдә үтә. Әлеге вакыт аралыгында Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә бик күп авырлыклар кичерергә туры килә: аңа иярүчеләр булса да, мөшрик булган халыкның күпчелеге аның дәгъватына колак салмый, алай гына да түгел – ачулана, тирги, мыскыллы сүзләр әйтә, кайберләре исә яный, хәтта төрле начарлыклар эшли. Әмма мөшрикләр аңа шундый рәхимсез, явыз мөгамәлә күрсәтүгә карамастан, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм барлык кыенлыкларны сабырлык белән кичереп, үзенә хас булган шәфкатьлелеген югалтмый.

Исламга өнди башлауга инде 10 ел тулган көннәрдә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм белән кызыклы да, гыйбрәтле дә бер хәл була. Дәгъват эшләре буенча ул Мәккә шәһәре чикләрен узып бер авылга юнәлгән чакта аның каршысына Мәккәнең мәшһүр көрәшчесе, алагаем авыр гәүдәле Рукан исемле баһадир очрый. Бу кеше Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең мәккәлеләргә сөйләгәннәрен аңламый һәм шуңа күрә аны яратмый иде, шул сәбәпле өндәү-нәсыйхәтләрен дә гел кире кага иде. Шәһәрнең күренекле шәхесен очраткач, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм аңа сәләм бирә һәм әйтә:

– Рукан, синең белән бераз сөйләшеп алырга мөмкинме?

Баһадир исә, сәләм кайтарып та тормыйча, кавемдәшенә горур карап, болай ди:

– Сөйләшербез, ләкин башта минем белән көрәшеп кара!

Аңлашыла ки, инде 50 яшен тутырган өлкән кешегә яшь, типсә тимер өзәрлек, моңарчы беркем дә җиңә алмаган көчле көрәшче белән бил алышу мәгънәсез гамәл кебек... Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләм фикере белән Раббысына мөрәҗәгать иткәннән соң, Руканның күзенә туры карап, әйтә:

– Яхшы, көрәшик. Ләкин башта җиңүчегә тиешле нәрсә булачагын килешик.

Ярышны оттырган кеше җиңүчегә бер сарык бирергә тиешлеген сөйләшкәннән соң, ике көндәш көрәшә башлый. Бер минут та узмый, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм Руканны егып аркасына сала. Нәрсә булганын аңлап та бетермәгән ир җиңелүен танырга мәҗбүр була, әмма моның ялгыш кына килеп чыккан очраклылык булуын әйтеп, тагын бер тапкыр көрәшеп карарга тәкъдим итә.

– Яхшы, ә бу юлы җиңечүгә бүләккә нәрсә була? – дип сораган пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә Рукан янә "сарык" дип җавап бирә.

Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең гайрәтен арттырамы, әллә тәкәббер көрәшчене зәгыйфьләндерәме — безгә мәгълүм түгел, шулай да, Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләм яңадан өстен чыгып җиңә. Аннары тагын берничә мәртәбә көрәшеп карыйлар һәм кабат-кабат җиңелгәннән соң, хәйран калган Рукан әйтә:

– Әй Мөхәммәд, гаҗәпләндердең... Моңарчы мине берәү дә калак сөягенә әйләндереп сала алмады... ә син... Гаҗә-әп...

Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм исә нурлы күз карашы илә елмаеп, болай ди:

– Әй Рукан, әйдә мин сиңа моннан да гаҗәебрәк булган бер нәрсә күрсәтәм! Күрәсеңме теге агачны?

Рукан күрсәтелгән тарафка борылгач, пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләм күркәм, әмма ышанычлы, нык тавыш белән боера:

– Әй агач! Аллаһ ризалыгы өчен кил минем яныма!

Шул ук мизгелдә куе ботаклы карт агач як-якка авыша-авыша селкенә башлый һәм тамырлары белән бергә җирдән аерылып, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә таба юнәлә. Моны карап торучы Рукан күзләрен зур итеп түгәрәкләп, авызын ачып шаккатып телсез кала. Агач исә Аллаһ рәсүле янына килеп җиткәч, бераз иелә дә итагатьле туктап кала. Шуннан соң, Мөхәммәд пәйгамбәр әмер биргәч, агач үз урынына барып, ничек элек торган – шулай урнаша.

Таң калган Рукан ни әйтергә дә белмичә бермәл сүзсез басып тора. Соңыннан тезләнеп пәйгамбәрне салләллаһу гәләйһи вә сәлләм кулларыннан тотып ала да, кычкырып җибәрә:

– Шәһадәт бирәм ки, Аллаһтан башка илаһ юк!!! Һәм шәһадәт бирәм ки, син – Аллаһның илчесе!!!

Әлеге кыйссадан шуны аңлап була: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм башкаларга хакыйкатьне җиткергәндә, аның каршыда булган әңгәмәдәшенең холкын, сәләтен, дәрәҗәсен исәпкә алып аралашырга тырышкан, ул аңлый торган телдә сөйләшкән. Җиңүчегә тиешле сарыкларны да ул, әлбәттә, алмый: әлеге шарт дөнья мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче, мин-минлек сыйфатына ия булган көрәшченең күңеленә керү, аны кызыктыру ысулы буларак кына әйтелә... Ә инде иң мөһиме - башкаларны дингә, иманга өндәгәндә сөекле пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләм ихлас Аллаһка тәвәккәлләп, йомшак сүзе, хикмәтле гамәле ярдәмендә кешенең акылына гына түгел, йөрәгенә дә тәэсир иткән.

■ **Ришат хәзрәт КУРАМШИН,**
Кукмара мәдрәсәсе мөдире,
**"Яшәеш сабаклары"** китабыннан

**ДҮШӘМБЕ**

07:00 Татарлар тарихы
07:40 Тәмле булсын
08:00 «Иң гүзәл исемнәр»
08:10 Онлайн-мәдрәсә
08:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
09:00 «Рухуль-Бәйан»
09:05 Хәдис дәресләре
09:25 Гаилә дәресләре
09:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
10:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
10:15 Һөнәрләр
10:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
10:40 Гыйбрәтле хикәяләр
10:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
11:05 Балам багалмам
11:25 «Бер хәдис – бер җавап»
11:35 Намазга өйрәник
12:00 Азан
12:05 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
12:25 «Дети в саду пророчества»
12:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:50 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
12:55 «Такой татарский русский»
13:00 «Узнаем у имама». Ислам дине турында актуаль сораулар
13:45 Гыйбрәтле хикәяләр
13:55 «Рухуль-Байян»
14:00 «Татарская география»
14:05 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән
14:15 «Мир Юсуфа» мультфильмы
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
16:00 Татарлар тарихы
16:40 Тәмле булсын
17:00 «Иң гүзәл исемнәр»
17:10 Онлайн-мәдрәсә
17:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
18:00 «Рухуль-Бәйан»
18:05 Хәдис дәресләре
18:25 Гаилә дәресләре
18:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
19:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
19:15 Һөнәрләр
19:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
19:40 Гыйбрәтле хикәяләр
19:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
20:05 Балам багалмам
20:30 «Бер хәдис – бер җавап»
20:40 Намазга өйрәник
21:00 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
21:20 «Дети в саду пророчества»
21:35 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
21:45 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
21:50 «Такой татарский русский»
21:55 «Узнаем у имама». Ислам дине турында актуаль сораулар
22:40 Гыйбрәтле хикәяләр
22:50 «Рухуль-Байян»
22:55 «Татарская география»
23:00 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән
23:10 «Мир Юсуфа» мультфильмы
23:25 Фәнни-танып-белү фильмы
23:55 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
00:55 Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән)

**СИШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ, ШИМБӘ**

07:00 Татарлар тарихы
07:40 Тәмле булсын
08:00 «Иң гүзәл исемнәр»
08:10 Онлайн-мәдрәсә
08:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
09:00 «Рухуль-Бәйан»
09:05 Хәдис дәресләре
09:25 Гаилә дәресләре
09:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
10:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
10:15 Һөнәрләр
10:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
10:40 Гыйбрәтле хикәяләр
10:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
11:05 Балам багалмам
11:25 «Бер хәдис – бер җавап»
11:35 Намазга өйрәник
12:00 Азан
12:05 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
12:25 «Так поступал Пророк»
12:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:50 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
12:55 «Такой татарский русский»
13:00 Халяль-лайфстайл
13:20 "Просто о главном" кыска метражлы фильмы
13:25 «Момент истины» Гали Габдесәлимов белән
13:40 «Сорок хадисов» мультфильмы
13:45 «Разговоры о важном»
13:55 «Рухуль-Байян»
14:00 «Татарская география»
14:05 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән
14:15 «Мир Юсуфа» мультфильмы
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
16:00 Татарлар тарихы
16:40 Тәмле булсын
17:00 «Иң гүзәл исемнәр»
17:10 Онлайн-мәдрәсә
17:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
18:00 «Рухуль-Бәйан»
18:05 Хәдис дәресләре
18:25 Гаилә дәресләре
18:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
19:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
19:15 Һөнәрләр
19:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
19:40 Гыйбрәтле хикәяләр
19:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
20:05 Балам багалмам
20:30 «Бер хәдис – бер җавап»
20:40 Намазга өйрәник
21:00 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
21:20 «Так поступал Пророк»
21:35 «Шөкер хуҗа» мультфильмы. Яңа сезон!
21:45 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
21:50 «Такой татарский русский»
21:55 Халяль-лайфстайл
22:15 "Просто о главном" кыска метражлы фильмы
22:20 «Момент истины» Гали Габдесәлимов белән
22:35 «Сорок хадисов» мультфильмы
22:40 «Разговоры о важном»
22:50 «Рухуль-Байян»
22:55 «Татарская география»
23:00 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән
23:10 «Мир Юсуфа» мультфильмы
23:25 Фәнни-танып-белү фильмы
23:55 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
00:55 Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән)

**ЧӘРШӘМБЕ, ҖОМГА**

07:00 Татарлар тарихы
07:40 Тәмле булсын
08:00 «Иң гүзәл исемнәр»
08:10 Онлайн-мәдрәсә
08:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
09:00 «Рухуль-Бәйан»
09:05 Хәдис дәресләре
09:25 Гаилә дәресләре
09:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
10:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
10:15 Һөнәрләр
10:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
10:40 Гыйбрәтле хикәяләр
10:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
11:05 Балам багалмам
11:25 «Бер хәдис – бер җавап»
11:35 Намазга өйрәник
12:00 Азан
12:05 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
12:25 «Дети в саду пророчества»
12:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы. Яңа сезон!
12:50 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
12:55 «Такой татарский русский»
13:00 «Узнаем у имама». Ислам дине турында актуаль сораулар
13:45 Гыйбрәтле хикәяләр
13:55 «Рухуль-Байян»
14:00 «Татарская география»
14:05 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон!
14:15 «Мир Юсуфа» мультфильмы
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
16:00 Татарлар тарихы
16:40 Тәмле булсын
17:00 «Иң гүзәл исемнәр»
17:10 Онлайн-мәдрәсә
17:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
18:00 «Рухуль-Бәйан»
18:05 Хәдис дәресләре
18:25 Гаилә дәресләре
18:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
19:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
19:15 Һөнәрләр
19:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
19:40 Гыйбрәтле хикәяләр
19:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
20:05 Балам багалмам
20:30 «Бер хәдис – бер җавап»
20:40 Намазга өйрәник
21:00 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
21:20 «Дети в саду пророчества»
21:35 «Шөкер хуҗа» мультфильмы. Яңа сезон!
21:45 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
21:50 «Такой татарский русский»
21:55 «Узнаем у имама». Ислам дине турында актуаль сораулар
22:40 Гыйбрәтле хикәяләр
22:50 «Рухуль-Байян»
22:55 «Татарская география»
23:00 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон!
23:10 «Мир Юсуфа» мультфильмы
23:25 Фәнни-танып-белү фильмы
23:55 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
00:55 Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән)

**ЯКШӘМБЕ**

07:00 Татарлар тарихы
07:40 Тәмле булсын
08:00 «Иң гүзәл исемнәр»
08:10 Онлайн-мәдрәсә
08:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
09:00 «Рухуль-Бәйан»
09:05 Хәдис дәресләре
09:25 Гаилә дәресләре
09:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
10:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
10:15 Һөнәрләр
10:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
10:40 Гыйбрәтле хикәяләр
10:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
11:05 Намазга өйрәник
11:30 Җомга вәгазе
12:00 Азан
12:05 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
12:25 «Дети в саду пророчества»
12:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы. Яңа сезон!
12:50 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
12:55 «Такой татарский русский»
13:00 «Узнаем у имама». Ислам дине турында актуаль сораулар
13:45 Гыйбрәтле хикәяләр
13:55 «Рухуль-Байян»
14:00 «Татарская география»
14:05 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон!
14:15 «Мир Юсуфа» мультфильмы
14:30 Фәнни-танып-белү фильмы
15:00 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
16:00 Татарлар тарихы
16:40 Тәмле булсын
17:00 «Иң гүзәл исемнәр»
17:10 Онлайн-мәдрәсә
17:40 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
18:00 «Рухуль-Бәйан»
18:05 Хәдис дәресләре
18:25 Гаилә дәресләре
18:50 «Җилкәй» анимацион фильмы
19:05 «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы
19:15 Һөнәрләр
19:30 «Сүз эчендә хикмәт бар»
19:40 Гыйбрәтле хикәяләр
19:55 «Рисәлә» Каюм Насыйри
20:05 Намазга өйрәник
20:30 Җомга вәгазе
21:00 «Әлифба. Коръән уку дәресләре»
21:20 «Дети в саду пророчества»
21:35 «Шөкер хуҗа» мультфильмы. Яңа сезон!
21:45 «Энциклопедия для маленьких мусульман»
21:50 «Такой татарский русский»
21:55 «Узнаем у имама». Ислам дине турында актуаль сораулар
22:40 Гыйбрәтле хикәяләр
22:50 «Рухуль-Байян»
22:55 «Татарская география»
23:00 «Хузур-вояж» Антон Кротов белән. Яңа сезон!
23:10 «Мир Юсуфа» мультфильмы
23:25 Фәнни-танып-белү фильмы
23:55 «Юнус Эмре. Путь любви» нәфис сериалы
00:55 Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән)

12+

# Казан өчен декабрь аена намаз вакытлары

| Көн | Көн исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Зәүвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01.12.2021 | Чәрш | 05:31 | 06:18 | 07:48 | 11:32 | 12:00 | 13:27 | 15:15 | 17:10 |
| 02.12.2021 | Пәнҗ | 05:32 | 06:20 | 07:50 | 11:32 | 12:00 | 13:26 | 15:15 | 17:10 |
| 03.12.2021 | Җом | 05:34 | 06:21 | 07:51 | 11:33 | 12:00 | 13:26 | 15:14 | 17:09 |
| 04.12.2021 | Шим | 05:35 | 06:23 | 07:53 | 11:33 | 12:00 | 13:25 | 15:13 | 17:09 |
| 05.12.2021 | Якш | 05:36 | 06:25 | 07:55 | 11:34 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:09 |
| 06.12.2021 | Дүш | 05:37 | 06:26 | 07:56 | 11:34 | 12:00 | 13:24 | 15:12 | 17:08 |
| 07.12.2021 | Сиш | 05:38 | 06:27 | 07:57 | 11:34 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:08 |
| 08.12.2021 | Чәрш | 05:39 | 06:29 | 07:59 | 11:35 | 12:00 | 13:23 | 15:11 | 17:08 |
| 09.12.2021 | Пәнҗ | 05:40 | 06:30 | 08:00 | 11:35 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 10.12.2021 | Җом | 05:41 | 06:31 | 08:01 | 11:36 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 11.12.2021 | Шим | 05:42 | 06:32 | 08:02 | 11:36 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 12.12.2021 | Якш | 05:43 | 06:34 | 08:04 | 11:37 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 13.12.2021 | Дүш | 05:44 | 06:35 | 08:05 | 11:37 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 14.12.2021 | Сиш | 05:45 | 06:36 | 08:06 | 11:38 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 15.12.2021 | Чәрш | 05:46 | 06:37 | 08:07 | 11:38 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 16.12.2021 | Пәнҗ | 05:47 | 06:37 | 08:07 | 11:39 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 17.12.2021 | Җом | 05:47 | 06:38 | 08:08 | 11:39 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 18.12.2021 | Шим | 05:48 | 06:39 | 08:09 | 11:40 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:09 |
| 19.12.2021 | Якш | 05:49 | 06:40 | 08:10 | 11:40 | 12:00 | 13:24 | 15:10 | 17:09 |
| 20.12.2021 | Дүш | 05:49 | 06:40 | 08:10 | 11:41 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:09 |
| 21.12.2021 | Сиш | 05:50 | 06:41 | 08:11 | 11:41 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:10 |
| 22.12.2021 | Чәрш | 05:50 | 06:41 | 08:11 | 11:42 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:10 |
| 23.12.2021 | Пәнҗ | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 11:42 | 12:00 | 13:26 | 15:12 | 17:11 |
| 24.12.2021 | Җом | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 11:43 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:12 |
| 25.12.2021 | Шим | 05:52 | 06:42 | 08:12 | 11:43 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:12 |
| 26.12.2021 | Якш | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:44 | 12:00 | 13:28 | 15:15 | 17:13 |
| 27.12.2021 | Дүш | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:44 | 12:00 | 13:28 | 15:15 | 17:14 |
| 28.12.2021 | Сиш | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:45 | 12:00 | 13:29 | 15:16 | 17:15 |
| 29.12.2021 | Чәрш | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:45 | 12:00 | 13:30 | 15:17 | 17:15 |
| 30.12.2021 | Пәнҗ | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 11:46 | 12:00 | 13:31 | 15:18 | 17:16 |
| 31.12.2021 | Җом | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 11:46 | 12:00 | 13:32 | 15:19 | 17:17 |

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Ноябрь саны, №11 (316)*

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Хәләфетдинова Л.Г.**, **Юлдашева А.И.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф.И.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең дана Заказ №2541
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170,04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 30 нчы ноябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 29 нчы ноябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.